соң шушы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 21 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча 700 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 100 м уза, шуннан соң 21 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көнбатышка таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, 21 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча 350 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 21 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буенча көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 21 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 200 м уза, шуннан соң 22 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 50 м 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
9 нчы кушымта

**Бөгелмә муниципаль районының «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Вязовка авыл җирлеге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Акбаш, Березовка, Зеленая Роща авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш.

Вязовка авыл җирлеге чиге Лениногорск муниципаль районы белән чиктәш җирдә Вязовка, Акбаш авыл җирлекләре һәм Лениногорск муниципаль районы чикләре тоташкан урында Коногоровка авылыннан 2,8 км көньякта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып Бөгелмә муниципаль районы чиге буйлап Вязовка, Березовка авыл җирлекләре һәм Лениногорск муници-

паль районы чикләре тоташкан урында Вязовка поселогыннан 2,4 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Вязовка авыл җирлеге чиге Березовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Березовка һәм Вязовка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Таллы Бүләк авылыннан 2,6 км көньякта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып Бөгелмә – Лениногорск автомобиль юлы буйлап көнбатышка таба 2,4 км 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Вязовка авыл җирлеге чиге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 2,2 км Бөгелмә – Коногоровка автомобиль юлына кадәр уза, шушы автомобиль юлы буйлап төньяк-көнчыгышка таба 650 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 100 м Вязовка авыл җирлеге, «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Зеленая Роща авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Вязовка авыл җирлеге чиге Зеленая Роща авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 850 м, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, сынык сызык ясап, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 95 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап 950 м, күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буенча 2,3 км уза, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,4 км, сынык сызык ясап, Бөгелмә – Уральск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 5,1 км Акбаш, Вязовка һәм Зеленая Роща авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Надеждино авылыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Вязовка авыл җирлеге чиге Акбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м, көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км уза, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман массивы буенча 100 м, Бөгелмә – Уральск ав-

томобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км бара, аннары шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буенча 1,5 км 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

### Бөгелмә муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Зеленая Роща авыл җирлеге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Акбаш, Вязовка, Кече Бөгелмә, Петровка һәм Спас авыл җирлекләре белән чиктәш.

Зеленая Роща авыл җирлеге чиге Акбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зеленая Роща, Акбаш һәм Вязовка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Надеждино авылыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып, ике мәртәбә Бөгелмә – Уральск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 300 м, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буенча 2,7 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буенча 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буенча 500 м, сынык сызык ясап, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 450 м профильле автомобиль юлына кадәр бара, шушы автомо-

биль юлы буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,1 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 1,2 км, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 6,4 км Зеленая Роща, Акбаш һәм Петровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Надеждино авылыннан 3,7 км көньякта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Зеленая Роща авыл җирлеге чиге Петровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 300 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км уза, шуннан соң урман полосасының көньяк чиге буенча көнчыгышка таба 500 м, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 100 м, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 106 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 50 м, төньяк-көнчыгышка таба 200 м бара, аннары 106 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м, 74 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча 200 м бара, аннары шушы урман кварталы буенча төньякка таба 300 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 900 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, «Бөгелмә —Уральск» — Надеждино — Сулы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы инешнең агымы буенча аска таба 1,9 км Сулы елгасына кадәр уза, әлеге елга агымы буенча аска таба 3,3 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, шуннан соң 36 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 200 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м, 36 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 200 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 106 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м Базаровка — Татар Димескәе автомобиль юлына кадәр бара, шушы автомобиль юлы буенча көньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 550 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 90 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча көньяк-көнчыгышка таба 100 м инешкә

кадәр уза, шушы инеш агымы буенча аска таба 1,3 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м, агач-куак массивы буенча 100 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 350 м һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 750 м уза, шуннан соң агач-куак массивы буенча көньяк-көнчыгышка таба 150 м һәм көньякка таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 250 м, ике мәртәбә Сулы елгасын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 150 м, төньяк-көнбатышка таба 100 м уза, шуннан соң 39 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 400 м бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң 39 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 700 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 250 м, 39 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м уза, шуннан соң шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 300 м бара, аннары урман полосасының көньяк чиге буенча көнчыгышка таба 400 м Солдат Чишмәсе инешенә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча өскә таба 2,0 км буага кадәр бара, шуннан соң шушы буаның сулъяк яры буенча төньякка таба 1,0 км уза, аннары яңадан Солдат Чишмәсе инеше агымы буенча өскә таба 2,1 км бара, шуннан соң 40 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 40 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 1,5 км бара, аннары 41 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 450 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 41 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 200 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 41 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м Зеленая Роща, Петровка һәм Спас авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ефановка авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Зеленая Роща авыл җирлеге чиге Спас авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 750 м уза, алга таба «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 100 м, сынык сызык ясап, 23 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш

чиге буенча 500 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 24 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, сынык сызык ясап, 24 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 650 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 300 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м, төньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 450 м, төньяк-көнчыгышка таба 350 м, төньяк-көнбатышка таба 550 м, 24 нче урман кварталының көньяк, көньяк-көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буенча көньяк-көнбатышка таба 550 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, 24 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м, 24 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 150 м бара, 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м уза, шуннан соң, агач-куак массивын һәм Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 2,5 км Зеленая Роща, Спас һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ефановка авылыннан 1,0 км көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Зеленая Роща авыл җирлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 1,8 км кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча аска таба 900 м аның Казачья елгасына койган урынына кадәр уза, шушы елга агымы буенча аска таба 50 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буенча 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 100 м, күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буенча 350 м Зеленая Роща, Кече Бөгелмә авыл җирлекләре һәм «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Зеленая Роща авыл җирлеге чиге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып, урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 750 м уза, шуннан соң урман полосасының көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 250 м, авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 50 м уза, алга таба буаның сулъяк яры буенча төньяк-көнбатышка таба 500 м, Казачья елгасы агымы буенча өскә таба 100 м Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына кадәр бара, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 700 м уза, аннары шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап төньякка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 650 м уза, шуннан соң Бөгелмә – Уральск автомобиль юлы буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 100 м, урман массивын, урман полосасын һәм Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, урман массивы чиге буйлап 250 м бара, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, аннары, сынык сызык ясап, шушы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 550 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 94 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 50 м бара, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м Зеленая Роща авыл җирлеге, «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Вязовка авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зеленая Роща авыл җирлеге чиге Вязовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 850 м, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, сынык сызык ясап, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан

Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 95 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап 950 м, күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буенча 2,3 км уза, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,4 км, сынык сызык ясап, Бөгелмә – Уральск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 5,1 км 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>11 нче кушымта

## Бөгелмә муниципаль районының «Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ключи авыл җирлеге Восточный, Кече Бөгелмә, Яңа Александровка һәм Яңа Сумароков авыл җирлекләре, Баулы һәм Ютазы муниципаль районнары белән чиктәш.

Ключи авыл җирлеге чиге Яңа Сумароков авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ключи, Яңа Сумароков һәм Яңа Александровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Аргуновка тимер юл разъезды поселогыннан 1,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,6 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 300 м, урман утыртмалары буенча 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк

чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 79 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, шуннан соң 79 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 450 м бара, шушы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча 250 м, 79 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 200 м уза, шушы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча 150 м Ключи, Яңа Сумароков авыл җирлекләре һәм Ютазы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Сумароков авылыннан 3,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Ключи авыл җирлеге чиге Ютазы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Бөгелмә муниципаль районы чиге буйлап Ключи авыл җирлеге, Ютазы һәм Баулы муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Акшуат авылыннан 3,2 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 30 нчы (75 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Ключи авыл җирлеге чиге Баулы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 30 нчы (75 нче) тоташу ноктасыннан алып Бөгелмә муниципаль районы чиге буйлап Ключи, Восточный авыл җирлекләре һәм Баулы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Еновка авылыннан 2,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ключи авыл җирлеге чиге Восточный авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 1,3 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 150 м, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 80 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 50 м бара, алга таба 5 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 1,3 км уза, аннары 5 нче, 2 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 850 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 2 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 150 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, шуннан соң 2 нче урман кварталының төньяк чиге буенча көнбатышка таба 900 м Ключи, Восточный һәм Кече Бөгелмә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Покровка авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Ключи авыл җирлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып, Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 600 м Ключи, Кече Бөгелмә һәм Яңа Александровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Покровка авылыннан 1,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ключи авыл җирлеге чиге Яңа Александровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 86 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м уза, аннары шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 1,1 км, зиратның көнчыгыш чиге буенча 50 м бара, шуннан соң зиратның төньяк чиге буенча көнбатышка таба 50 м, 86 нчы урман кварталының төньяк чиге буенча 350 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман массивының көньяк чиге буенча 50 м, 86 нчы урман кварталының төньяк чиге буенча 200 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 86 нчы, 85 нче урман кварталларының төньяк чиге буенча 1,3 км уза, аннары Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 700 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 100 м, төньякка таба 650 м, көнчыгышка таба 100 м, Зур Покровка – Акшуат һәм Бөгелмә – Азнакай автомобиль юлларын тоташтыра торган профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп,төньякка таба 500 м, 61 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча төньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 200 м, төньяк-көнчыгышка таба 750 м, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 650 м бара, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км, кибеп баручы инешне һәм урман утыртмаларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м уза, аннары урман утыртмаларының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 100 м, урман утыртмалары буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 111 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 50 м бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, шуннан соң, яңадан кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 40 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба

100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, аннары урман полосасының көнбатыш чиге буенча төньякка таба 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көнбатыш чиге буенча 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көнбатыш чиге буенча 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м, урман полосасының көнбатыш чиге буенча 150 м бара, шуннан соң Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>12 нче кушымта

**Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кодаш авыл җирлеге «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Азнакай һәм Әлмәт муниципаль районнары белән чиктәш.

Кодаш авыл җирлеге чиге Әлмәт муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кодаш авыл җирлеге, «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге һәм Әлмәт муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кодаш авылыннан 3,6 км көнбатышта урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Бөгелмә муниципаль районы чиге буйлап Кодаш авыл җирлеге, Әлмәт һәм Азнакай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кызыл Чишмә авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 3 нче (73 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Кодаш авыл җирлеге чиге Азнакай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 3 нче (73 нче) тоташу ноктасыннан алып Бөгелмә муниципаль районы чиге буйлап «Карабаш шәһәр ти-

бындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Кодаш авыл җирлеге һәм Азнакай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кызыл Чишмә авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кодаш авыл җирлеге чиге «Карабаш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып профильле автомобиль юлы буйлап көньяк-көнчыгышка таба 2,3 км, сынык сызык ясап, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буенча 50 м, Кодаш елгасын кисеп үтеп, сазлык буйлап 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 300 м, Карабаш – Актүбә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 200 м, көньяк-көнчыгышка таба 550 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 400 м уза, шуннан соң карьер буйлап төньяк-көнчыгышка таба 100 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 550 м уза, шуннан соң «Әлмәт урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кама-Исмәгыйль участок урманчылыгындагы 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 134 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м, көнчыгышка таба 850 м, көньяк-көнчыгышка таба 450 м бара, аннары 139 нчы урман кварталының төньяк чиге буенча көнчыгышка таба 100 м, төньяк-көнчыгышка таба 450 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 150 м, 139 нчы урман кварталының төньяк чиге буенча 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 139 нчы урман кварталының төньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 250 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 140 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 400 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 140 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 135 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча

100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 135 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 800 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 200 м, 135 нче урман кварталының төньяк чиге буенча 150 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, аннары 135 нче урман кварталының төньяк чиге буенча көнчыгышка таба 100 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, көнчыгышка таба 400 м уза, шуннан соң, Щиксаз инешен кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 900 м, 165 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча 100 м бара, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м Кызыл Чишмә елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча өскә таба 350 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 250 м уза, шуннан соң «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 44 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча көньяк-көнчыгышка таба 400 м, 84 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 100 м 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
13 нче кушымта

**Бөгелмә муниципаль районының «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Кече Бөгелмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Березовка, Восточный, Зеленая Роща, Ключи, Яңа Александровка, Спас, Иске Исаково авыл җирлекләре белән чиктәш.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Березовка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Бөгелмә, Березовка һәм Яңа Александровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бөгелмә авылыннан 150 м төньяк-көнбатышта Зәй елгасында урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып Зәй елгасы агымы буенча өскә таба 1,8 км аңа Бөгелмә елгасы койган җиргә кадәр уза, шушы елганың агымы буенча өскә таба 6,5 км Березовка, Кече Бөгелмә авыл җирлекләре һәм «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Кече Бөгелмә авылыннан 100 м төньяк-көнбатышта Бөгелмә елгасы үзәнендә урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Яңа Александровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып Зәй елгасы агымы буенча аска таба 1,3 км уза, шуннан соң, яр буе агач-куак полосасын, текә ярны һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 500 м бара, аннары, яңадан профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм дамбаны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 300 м, көньякка таба 100 м, көньяк-көнбатышка таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, шуннан соң 92 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 200 м, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, 92 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, шуннан соң, ике мәртәбә профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, 92 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 550 м уза, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м, сынык сызык ясап, 92 нче урман кварталының көньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км һәм, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 550 м бара, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 400 м, 92 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-

көнчыгыш чиге буенча 250 м уза, Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буенча 350 м бара, шуннан соң «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 650 м уза, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буенча көнбатышка таба 100 м бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 200 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньякка таба 300 м, 82 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 1 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буенча 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м бара, аннары 1 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 250 м, көньяк-көнчыгышка таба 250 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 500 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м, аннары, сынык сызык ясап, 1 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 150 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 1 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 650 м бара, шуннан соң, Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 200 м уза, аннары «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөгелмә участок урманчылыгындагы 92 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 900 м һәм, сынык сызык ясап, көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 1,0 км уза, аннары, сынык сызык ясап,

89 нчы урман кварталының көньяк чиге буенча көнбатышка таба 750 м һәм көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 750 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 50 м бара, шуннан соң Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 350 м уза, аннары 85 нче, 86 нчы урман кварталларының көньяк чиге буенча көнчыгышка таба 1,2 км бара, шуннан соң 86 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньякка таба 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м Кече Бөгелмә, Яңа Александровка һәм Ключи авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Покровка авылыннан 1,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Ключи авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Бөгелмә, Ключи һәм Восточный авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Покровка авылыннан 1,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып, Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 600 м 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Восточный авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап көньякка таба 750 м, төньяк-көнбатышка таба 700 м, көньяк-көнбатышка таба 400 м уза, шуннан соң 2 нче, 3 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 300 м бара, 3 нче, 6 нчы урман кварталларының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буенча көньяк-көнбатышка таба 1,3 км уза, шуннан соң 6 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 300 м, аннары, сынык сызык ясап, 6 нчы, 8 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 850 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 8 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча 150 м бара, шуннан соң 8 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча көнчыгышка таба 300 м, көньяк-көнчыгышка таба 100 м, көньяк-көнбатышка таба 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, шуннан соң 8 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньякка таба 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 300 м уза, шуннан соң 8 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньякка таба 250 м уза, аннары, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 450 м

һәм көньяк-көнчыгышка таба 450 м бара, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, аннары 81 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м, 13 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча 200 м уза, шуннан соң шушы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 21 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча 700 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 100 м уза, шуннан соң 21 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча көнбатышка таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, 21 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча 350 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 21 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көньяк чикләре буенча көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 21 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 200 м уза, шуннан соң 22 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 50 м Кече Бөгелмә, Восточный һәм Иске Исаково авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Алга поселогыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Иске Исаково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 24 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 550 м уза, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча көнбатышка таба 50 м бара, аннары 20 нче урман кварталының төньяк чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 200 м һәм төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 200 м бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 600 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм,

Бәкер елгасын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 150 м бара, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 50 м, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 100 м бара, шуннан соң 83 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча көнчыгышка таба 150 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 650 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, аннары 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 400 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м, көньяк-көнбатышка таба 100 м, көньякка таба 200 м уза, шуннан соң 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча көнчыгышка таба 900 м бара, аннары 20 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча көньякка таба 1,0 км Кече Бөгелмә, Иске Исаково һәм Спас авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Алга поселогыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Спас авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 150 м һәм көньяк-көнбатышка 150 м уза, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 50 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м бара, аннары 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка таба 250 м һәм көньяк-көнбатышка таба 250 м уза, шуннан соң 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 200 м һәм төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 350 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м һәм көньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 300 м, төньяк-көнбатышка таба 850 м, шуннан соң урман полосасының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 350 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 250 м уза, 83 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, 83 нче урман

кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 100 м, төньяк-көнбатышка таба 100 м уза, аннары 19 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, 19 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 400 м уза, аннары, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Бөгелмә – Татар Димескәе» – Алга автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 2,2 км уза, шуннан соң әлеге автомобиль юлы полосасының төньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 2,4 км, Зәй елгасын һәм инешне кисеп үтеп, көнбатышка таба 2,0 км Кече Бөгелмә, Спас һәм Зеленая Роща авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ефановка авылыннан 1,0 км көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге Зеленая Роща авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 1,8 км кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча аска таба 900 м аның Казачья елгасына койган урынына кадәр уза, шушы елга агымы буенча аска таба 50 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буенча 550 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 100 м, күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буенча 350 м Кече Бөгелмә, Зеленая Роща авыл җирлекләре һәм «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Забугоровка авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кече Бөгелмә авыл җирлеге чиге «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 350 м уза, шуннан соң урман массивы буйлап төньяк-көнчыгышка таба 450 м бара, аннары, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 450 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап көньяк-көнбатышка таба 450 м бара, аннары, буа плотинасын һәм Казачья елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 100 м уза, шуннан соң, урман полосасын

кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 500 м бара, урман массивын, агач-куак массивын, инешне, Зәй елгасын һәм яр буе агач-куак массивларын кисеп үтеп, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 4,8 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 50 м, текә ярны, инешне һәм урман массивын кисеп үтеп, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м Бөгелмә – Татар Димескәе автомобиль юлына кадәр бара, аннары шушы автомобиль юлы буенча төньяк-көнбатышка таба 900 м бара, шуннан соң, инешне һәм аның текә ярларын, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 900 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м буага кадәр уза, буаның уңъяк яры буйлап көньякка таба 400 м уза, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, буаның сулъяк яры буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км буа плотинасына кадәр бара, аннары, сынык сызык ясап, Бөгелмә – Татар Димескәе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 500 м бара, аннары шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 400 м уза, юл буе урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 700 м профильле автомобиль юлына кадәр уза, шуннан соң шушы автомобиль юлы буйлап төньяк-көнбатышка таба 400 м бара, Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлы буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км уза, аннары күмәк бакчаларның көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 50 м бара, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 50 м 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

**Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Наратлы авыл җирлеге Спас, Иске Исаково, Татар Димескәе авыл җирлекләре, Баулы муниципаль районы һәм Оренбург өлкәсе белән чиктәш.

Наратлы авыл җирлеге чиге Баулы муниципаль районы белән чиктәш җирдә Наратлы, Иске Исаково авыл җирлекләре һәм Баулы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Петровка поселогыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта Димескә елгасында урнашкан 47 нче тоташу ноктасыннан алып Бөгелмә муниципаль районы чиге буйлап Наратлы авыл җирлеге, Баулы муниципаль районы һәм Оренбург өлкәсе чикләре тоташкан урында Ключевка авылыннан 4,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче (24 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Наратлы авыл җирлеге чиге Оренбург өлкәсе белән чиктәш җирдә 32 нче (24 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Наратлы, Татар Димескәе авыл җирлекләре һәм Оренбург өлкәсе чикләре тоташкан урында Татар Димескәе авылыннан 4,0 км көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Наратлы авыл җирлеге чиге Татар Димескәе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, «Баулы урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баулы участок урманчылыгындагы 131 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 300 м, 130 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча 50 м уза, 131 нче

урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 700 м, Димескә елгасын һәм аның текә уңъяк ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км, агач-куак массивы буенча 150 м инешкә кадәр уза, инеш агымы буенча өскә таба 250 м Шайтан елгасына кадәр уза, «Бөгелмә — Татар Димескәе» — Наратлы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шушы елга агымы буенча өскә таба 2,1 км Гремячка елгасы тамагына кадәр бара, Гремячка елгасы агымы буенча өскә таба 30 м Наратлы, Татар Димескәе һәм Спас авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Райлан авылыннан 650 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Әлеге картографик тасвирлама «Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Спас авыл җирлеге Зеленая Роща, Кече Бөгелмә, Наратлы, Петровка, Иске Исаково һәм Татар Димескәе авыл җирлекләре белән чиктәш.

Спас авыл җирлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Спас, Кече Бөгелмә һәм Иске Исаково авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Алга поселогыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 150 м һәм көньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 50 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 350 м бара, аннары 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка таба 250 м һәм көньяк-көнбатышка таба 250 м уза, шуннан соң 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 200 м һәм төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 350 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м һәм көньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 300 м, төньяк-көнбатышка таба 850 м уза, шуннан соң урман полосасының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 350 м бара,

аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 250 м уза, 83 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, 83 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 100 м, төньяк-көнбатышка таба 100 м уза, аннары 19 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м, 19 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 400 м уза, аннары, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Бөгелмә – Татар Димескәе» – Алга автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 2,2 км уза, шуннан соң әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 2,4 км, Зәй елгасын һәм инешне кисеп үтеп, көнбатышка таба 2,0 км Спас, Кече Бөгелмә һәм Зеленая Роща авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ефановка авылыннан 1,0 км көнбатышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Спас авыл җирлеге чиге Зеленая Роща авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Спас, Зеленая Роща һәм Петровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ефановка авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 750 м уза, шуннан соң «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 100 м, сынык сызык ясап, 23 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 500 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 24 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, сынык сызык ясап, 24 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 650 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 300 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м, төньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 450 м, төньяк-көнчыгышка таба 350 м, төньяк-көнбатышка таба 550 м, 24 нче урман кварталының көньяк, көньяк-көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буенча көньяк-көнбатышка таба 550 м

бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, 24 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 50 м, 24 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 150 м бара, 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м һәм, агач-куак массивын һәм Казан — Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 2,5 км 22 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Спас авыл җирлеге чиге Петровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 41 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, 41 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 400 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 2,7 км уза, аннары 26 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буенча төньякка таба 600 м уза, шуннан соң шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча көнбатышка таба 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 25 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 50 м бара, урман массивының төньяк чиге буенча 150 м, 25 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 50 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, 25 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 200 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 600 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, 25 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, сынык сызык ясап, 25 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча төньякка таба 350 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 250 м, 25 нче урман кварталының төньяк чиге буенча 450 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары 25 нче урман кварталының төньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 500 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, 25 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 200 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м, 25 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба

200 м, 25 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 100 м бара, аннары 26 нчы урман кварталының төньяк чиге буенча көнчыгышка таба 50 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, 26 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 500 м бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 700 м уза, шуннан соң 26 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньякка таба 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м, 98 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 800 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 150 м, сынык сызык ясап, 56 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 550 м уза, аннары, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 550 м, 55 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 250 м бара, 55 нче, 59 нчы урман кварталларының көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 1,7 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 500 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м уза, шуннан соң 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 300 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м уза, шуннан соң 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 200 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 61 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 250 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 61 нче, 63 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 1,3 км бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 63 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 550 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 63 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м уза, шуннан соң 64 нче урман кварталының төньяк чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 64 нче урман кварталының төньяк чиге буенча 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м бара, аннары,

сынык сызык ясап, 64 нче, 68 нче урман кварталларының төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буенча көньяк-көнчыгышка таба 2,0 км уза, шуннан соң 96 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 68 нче, 69 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 900 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 69 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 69 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көнчыгышка таба 250 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м, 69 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м бара, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң 69 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буенча төньякка таба 200 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 500 м бара, 70 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 150 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, шушы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 800 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м уза, шуннан соң 70 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 50 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м уза, сынык сызык ясап, 70 нче, 66 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча 750 м бара, шуннан соң 66 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш, төньяк һәм көнчыгыш чикләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км һәм көньяк-көнчыгышка таба 350 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 50 м, 66 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 66 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буенча 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 66 нчы, 70 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 450 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 70 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 250 м Спас, Петровка һәм Татар Димескәе авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Димескәе авылыннан 3,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Спас авыл җирлеге чиге Татар Димескәе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреж-

дениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 95 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 300 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка таба 250 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман массивы буйлап 50 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м бара, шуннан соң урман массивы буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м, урман массивы буйлап 200 м, сынык сызык ясап, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,4 км аның Гремячка елгасына койган җиренә кадәр уза, Бөгелмә — Татар Димескәе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча аска таба 5,8 км Спас, Татар Димескәе һәм Наратлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Райлан авылыннан 650 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Спас авыл җирлеге чиге Наратлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып, Шайтан елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 34 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча 300 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, 34 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча 200 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м һәм төньяк-көнбатышка таба 250 м уза, аннары 5 нче, 4 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буенча 650 м бара, шуннан соң 4 нче урман кварталының көнбатыш чиге буенча төньякка таба 200 м уза, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 600 м, 93 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 250 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 33 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 33 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 150 м Спас, Наратлы һәм Иске Исаково авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Спас авылыннан 2,1 км көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Спас авыл җирлеге чиге Иске Исаково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 30 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, төньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, аннары 30 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 50 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 200 м, 30 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м, сынык сызык ясап, 30 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 450 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, аннары 29 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнчыгышка таба 250 м, 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м һәм төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, 29 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка таба 200 м бара, аннары 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, шуннан соң 29 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,1 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, шуннан соң 29 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 300 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 500 м, 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 250 м бара, урман полосасы буенча 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, 20 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 50 м 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

**Бөгелмә муниципаль районының «Иске Исаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Исаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Исаково авыл җирлеге Восточный, Keче Бөгелмә, Наратлы, Спас авыл җирлекләре һәм Баулы муниципаль районы белән чиктәш.

Иске Исаково авыл җирлеге чиге Кече Бөгелмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Исаково, Кече Бөгелмә һәм Восточный авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Алга поселогыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 550 м уза, шуннан соң «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча көнбатышка таба 50 м бара, аннары 20 нче урман кварталының төньяк чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 200 м һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 200 м бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 600 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча 300 м, Бәкер елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап 150 м һәм көньяк-көнбатышка таба 150 м бара, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 50 м, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң 83 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 150 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 650 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, аннары 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 400 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м, көньяк-көнбатышка таба 100 м, көньякка таба 200 м уза, шуннан соң 19 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлеге буенча көнчыгышка таба 900 м бара, аннары 20 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 1,0 км Иске Исаково, Кече Бөгелмә һәм Спас авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Алга поселогыннан 1,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Исаково авыл җирлеге чиге Спас авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Исаково, Спас һәм Наратлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Спас авылыннан 2,1 км көнчыгышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасыннан алып «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 30 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м бара, төньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, аннары 30 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 50 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 200 м, 30 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м, сынык сызык ясап, 30 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 450 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, аннары 29 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 250 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнчыгышка таба 250 м бара, 29 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м һәм төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, 29 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы

җирләре буенча төньякка таба 200 м бара, аннары 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 500 м, 29 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, шуннан соң 29 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,1 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, шуннан соң 29 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 300 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 500 м, 27 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 250 м бара, урман полосасы буйлап 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м, 20 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 50 м 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Исаково авыл җирлеге чиге Наратлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 31 нче тоташу ноктасыннан алып урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 50 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 31 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 600 м бара, аннары 30 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 200 м, аннары, сынык сызык ясап, 30 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буенча төньякка таба 550 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 200 м, 30 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 450 м бара, 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м уза, 30 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 100 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, шуннан соң 30 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 150 м, көньякка таба 250 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 250 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 250 м уза, 30 нчы урман кварталының төньяк чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 30 нчы, 31 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буенча

250 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м, төньяк-көнчыгышка таба 500 м, көньяк-көнчыгышка таба 100 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,5 км бара, аннары урман массивларының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 50 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң «Баулы урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баулы участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 200 м һәм төньяк-көнбатышка таба 300 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 150 м, 2 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 50 м, 2 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 2 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 450 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м уза, аннары 2 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 350 м кибеп баручы инешкә кадәр бара, шушы инеш агымы буенча аска таба 3,0 км уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Казан – Оренбург» – Петровка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км, инешләрне кисеп үтеп, агач-куак массивы буенча 400 м Димескә елгасына кадәр бара, аннары, Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Димескә елгасы агымы буенча аска таба 3,3 км Иске Исаково, Наратлы авыл җирлекләре һәм Баулы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Петровка поселогыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта Димескә елгасында урнашкан 47 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Исаково авыл җирлеге чиге Баулы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 47 нче тоташу ноктасыннан алып Бөгелмә муниципаль районы чиге буйлап Иске Исаково, Восточный авыл җирлекләре һәм Баулы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Еновка авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта Зябейка елгасында урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Исаково авыл җирлеге чиге Восточный авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 46 нчы тоташу ноктасыннан алып Зябейка елгасы агымы буенча аска таба 600 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буенча 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-

көнбатыш чиге буенча 700 м, сынык сызык ясап, «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 15 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 300 м, 81 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 15 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча 150 м уза, шуннан соң 15 нче урман кварталының шушы аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 15 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 500 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 15 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 350 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 350 м, төньякка таба 150 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м уза, аннары 85 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 500 м һәм, урман утыртмаларын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 350 м Казан – Оренбург федераль автомобиль юлына кадәр уза, аннары Казан – Оренбург федераль автомобиль юлы буенча көньяк-көнчыгышка таба 650 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 650 м, сынык сызык ясап, 22 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча көньякка таба 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, сынык сызык ясап, 22 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча көньякка таба 550 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 22 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча 50 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, шуннан соң 22 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, сынык сызык ясап, берничә мәртәбә Бәкер елгасын кисеп үтеп, 22 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буенча 550 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 400 м, сынык сызык ясап, 22 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буенча 800 м 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

**Бөгелмә муниципаль районының «Татар Димескәе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Татар Димескәе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Татар Димескәе авыл җирлеге Наратлы, Петровка, Спас авыл җирлекләре һәм Оренбург өлкәсе белән чиктәш.

Татар Димескәе авыл җирлеге чиге Петровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Татар Димескәе, Петровка һәм Спас авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Димескәе авылыннан 3,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып «Баулы урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баулы участок урманчылыгындагы 117 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 700 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 50 м, 117 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, 117 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м бара, 117 нче, 121 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 850 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 121 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көнчыгышка таба 600 м бара, аннары 121 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 500 м бара, сынык сызык ясап, 125 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м һәм көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, 125 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 650 м, 125 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнчыгышка таба 200 м,

көньяк-көнбатышка таба 400 м, төньяк-көнбатышка таба 100 м уза, аннары 125 нче урман кварталының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 500 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, 125 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, шуннан соң әлеге урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 550 м бара, аннары 124 нче, 126 нчы урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 500 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м һәм көньяк-көнбатышка таба 50 м бара, 126 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м Базаровка – Татар Димескәе автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 800 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 126 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м бара, 126 нчы, 123 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, 123 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка таба 250 м, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, 123 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, 123 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м бара, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м уза, шуннан соң 120 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 350 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, 120 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, 120 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, аннары 119 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көнбатышка таба 50 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м бара, шуннан соң 119 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 50 м, төньяк-көнбатышка таба 150 м, көньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, шуннан соң 119 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньякка таба 200 м уза, шуннан соң 119 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 300 м, көньяк-көнбатышка таба 100 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 122 нче урман кварталының көнчыгыш

чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,1 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка таба 100 м бара, аннары 122 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 100 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 100 м һәм төньяк-көнбатышка таба 100 м бара, аннары 122 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 50 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, сынык сызык ясап, 122 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, шуннан соң 122 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 122 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 800 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 300 м уза, аннары 118 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 50 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнбатышка таба 600 м һәм төньяк-көнбатышка таба 350 м уза, аннары 118 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка таба 300 м, 118 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, аннары, сазлыкны, Сулы елгасын һәм яр буе агач-куак массивларын, Базаровка – Татар Димескәе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 250 м һәм көньяк-көнбатышка таба 2,3 км, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 250 м, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, урман массивы буенча 300 м, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 450 м Татар Димескәе, Петровка авыл җирлекләре һәм Оренбург өлкәсе чикләре тоташкан урында Сулы авылыннан 2,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Татар Димескәе авыл җирлеге чиге Спас авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Петровка участок урманчылыгындагы 95 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 300 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка таба 250 м, урман массивының көньяк-

көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман массивы буйлап 50 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м бара, шуннан соң урман массивы буенча төньяк-көнчыгышка таба 150 м уза, аннары урман массивының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 250 м, урман массивы буенча 200 м, сынык сызык ясап, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м инешкә кадәр бара, әлеге инеш агымы буенча аска таба 1,4 км аның Гремячка елгасына койган җиренә кадәр уза, Бөгелмә – Татар Димескәе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча аска таба 5,8 км Татар Димескәе, Спас һәм Наратлы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Райлан авылыннан 650 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Татар Димескәе авыл җирлеге чиге Наратлы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Татар Димескәе, Наратлы авыл җирлекләре һәм Оренбург өлкәсе чикләре тоташкан урында Татар Димескәе авылыннан 4,0 км көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасыннан алып урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м, «Баулы урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Баулы участок урманчылыгындагы 131 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, 130 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, 131 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, Дим елгасын һәм аның текә уңъяк ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,6 км, агач-куак массивы буйлап 150 м инешкә кадәр уза, Шайтан елгасы агымы буенча өскә таба 250 м уза, «Бөгелмә – Татар Димескәе» – Наратлы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, әлеге елга агымы буенча өскә таба 2,1 км Гремячка елгасы тамагына кадәр бара, Гремячка елгасы агымы буенча өскә таба 30 м 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Татар Димескәе авыл җирлеге чиге Оренбург өлкәсе белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасының административ чиге буйлап 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 22 ноябре
№ 103-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1206. «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 7 (I өлеш), 2 – 24 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Әгерҗе муниципаль районы Удмурт Республикасы, Менделеевск, Тукай һәм Минзәлә муниципаль районнары белән чиктәш.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Әгерҗе, Менделеевск муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Барҗы-Умга авылыннан 8,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче (18 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Әгерҗе, Минзәлә муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Зуево авылыннан 3,8 км көньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 40 нчы (19 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 23 нче (18 нче) тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап көньяк-көнчыгышка таба 350 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 4,2 км Әгерҗе, Менделеевск һәм Тукай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Барҗы-Умга авылыннан 12,5 км көньяк-көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 495120,20, Y = 2338386,60 координаталы 24 нче (66 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 24 нче (66 нчы) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап көнчыгышка таба 5,0 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 7,7 км, сынык сызык ясап, көнчыгышка таба 13,7 км Әгерҗе, Тукай һәм Минзәлә муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Мадьяр авылыннан 6,1 км көньяк-көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 490060,59, Y = 2358089,50 координаталы 37 нче (67 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 40 нчы (19 нчы) тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап көнбатышка таба 2,9 км, төньяк-көнбатышка таба 4,1 км, көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң яңадан төньяк-көнбатышка таба 900 м, сынык сызык ясап, берничә утрауны кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 3,3 км бара, сынык сызык ясап, берничә утрауны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 7,9 км бара, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 700 м, төньяк-көнбатышка таба 700 м, көньяк-көнбатышка таба 650 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, берничә утрауны кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 1,6 км, берничә утрауны кисеп үтеп, төньякка таба 350 м бара, аннары, сынык сызык ясап, берничә утрауны кисеп үтеп, төньяк-

көнбатышка таба 2,3 км, төньяк-көнчыгышка таба 700 м һәм төньяк-көнбатышка таба 700 м 37 нче (67 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлекләре чикләре Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә түбәндәгечә уза:

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Иж-Бубый авылыннан 8,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буенча 1 нче тоташу ноктасына кадәр;

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Кадрәк авылыннан 6,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр;

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Кадрәк авылыннан 7,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 45 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буенча 45 нче тоташу ноктасына кадәр.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

## Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Иж-Бубый авыл җирлеге һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

«Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге, Иж-Бубый авыл җирлеге һәм Удмурт Республикасы

чикләре тоташкан урында Иж-Бубый авылыннан 3,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге, Иж-Бубый авыл җирлеге һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Иж-Бубый авылыннан 5,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Иж-Бубый авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып, инешне кисеп үтеп, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әгерҗе участок урманчылыгындагы 28 нче, 27 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 2,0 км, Иж елгасын кисеп үтеп, 29 нчы урман кварталы буенча 450 м, урман һәм агач-куак массивларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км, агач-куак полосасы буенча 50 м, урман массивы буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, канауны кисеп үтеп, урман массивы буйлап 700 м һәм көнбатышка таба 200 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,3 км, урман полосасының көньяк чиге буйлап 450 м бара, шуннан соң, Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 650 м уза, аннары урман полосасының көньяк чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 400 м бара, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м уза, урман полосасының көньяк чиге буйлап 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 650 м, 22 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м һәм 121 нче урман кварталы буенча 350 м 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Иж-Бубый авылыннан 8,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 1 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

## Әгерҗе муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Азево авыл җирлеге Бима, Красный Бор, Күләгәш, Салагыш һәм Иске Чекалда авыл җирлекләре белән чиктәш.

Азево авыл җирлеге чиге Бима авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Азево, Бима һәм Иске Чекалда авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Чекалда авылыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 650 м, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Красный Бор участок урманчылыгындагы 157 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буенча 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 155 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 150 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 950 м һәм 155 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буенча 40 м инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буйлап аска таба 850 м аның башка инеш белән кушылган җиренә кадәр бара, аннары инеш агымы буенча аска таба 900 м аның Зур Пеләмеш елгасына койган җиренә кадәр уза, әлеге елганы кисеп үтә һәм 7 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 300 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 900 м бара, шуннан соң 159 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 250 м, урман массивы буенча 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м уза, аннары 155 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 350 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 100 м, 155 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буенча 350 м һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м бара, 155 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, Юмэнер-Вюд елгасын кисеп үтеп, 28 нче, 29 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча 2,7 км уза, аннары 51 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап көньякка таба 600 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 550 м Азево, Бима һәм Күләгәш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Күләгәш авылыннан 1,8 км төньякта урнашкан 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

көнбатышка таба 150 м уза, шуннан соң 80 нче, 72 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 2,0 км «Әгерҗе – Красный Бор» – Салагыш автомобиль юлына кадәр бара, шушы юлга бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буенча көнчыгышка таба 150 м уза, аннары, сынык сызык ясап, «Әгерҗе – Красный Бор» – Салагыш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм канауны кисеп үтеп, 65 нче, 59 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км бара, шуннан соң, Азево елгасын, инешне һәм сазлыкны кисеп үтеп, 59, 47, 34, 23 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 4,1 км 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Салагыш авыл җирлеге чиге Красный Бор авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Салагыш, Красный Бор авыл җирлекләре һәм Минзәлә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Красный Бор авылыннан 4,3 км көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә исемсез утрауда урнашкан X = 488080,57, Y = 2360220,98 координаталы 38 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба агач-куак массивы буйлап 100 м уза, Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча 750 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 1,9 км бара, аннары «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Красный Бор участок урманчылыгындагы 135, 133, 125 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 2,3 км төньякка таба, шуннан соң 125 нче, 126 нчы урман кварталларының төньяк чиге буенча көнчыгышка таба 2,1 км бара, аннары 116 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап төньякка таба 950 м, 116 нчы, 106 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Салагыш авыл җирлеге чиге Минзәлә муниципаль районы белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып Әгерҗе муниципаль районы чиге буйлап Салагыш авыл җирлеге, Минзәлә һәм Тукай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Мадьяр авылыннан 6,1 км көньяк-көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 490060,59, Y=2358089,50 координаталы 37 нче (67 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Салагыш авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 37 нче (67 нче) тоташу ноктасыннан алып Әгерҗе муниципаль районы чиге буенча Салагыш авыл җирлеге, Тукай һәм Менделеевск муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Баржы-Умга авылыннан 12,5 км көньяк-көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан

X = 495120,20, Y = 2338386,60 координаталы 24 нче (66 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Салагыш авыл җирлеге чиге Менделеевск муниципаль районы белән чиктәш җирдә 24 нче (66 нчы) тоташу ноктасыннан алып Әгерҗе муниципаль районы чиге буйлап Салагыш авыл җирлеге, Менделеевск муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Барҗы-Умга авылыннан 8,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче (18 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Салагыш авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 23 нче (18 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буенча 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
19 нчы кушымта

## Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Сарсак-Умга авыл җирлеге Кодаш, Тирсә, Яңа Бәзәкә, Тәбәрле авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Сарсак-Умга авыл җирлеге чиге Кодаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сарсак-Умга, Кодаш һәм Тирсә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарсак-Умга авылыннан 950 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 300 м, урман массивының көньяк чиге буенча 100 м, Сарсак-Умга һәм Иске Кызылъяр авылларын тоташтыра торган профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны

һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м Чаж елгасына кадәр уза, аның агымы буенча өскә таба 750 м аның элеккеге үзәненә кадәр бара, Чаж елгасының элеккеге үзәне буйлап көньяк-көнчыгышка таба 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 250 м уза, Чаж елгасы агымы буенча яңадан өскә таба 1,1 км аңа Сарсак елгасы койган җиргә кадәр бара, шушы елга агымы буйлап өскә таба 3,8 км уза, шуннан соң, Сарсак елгасының текә сулъяк ярын һәм сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 200 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,8 км кибеп баручы инешкә кадәр бара, шушы инеш агымы буйлап аска таба 400 м аның башка кибеп баручы инеш белән кушылган җиренә кадәр уза һәм шушы инеш агымы буенча өскә таба 1,9 км Сарсак-Умга, Кодаш авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Татар Таңсары авылыннан 3,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Сарсак-Умга авыл җирлеге чиге Тирсә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 100 м, Тирсә – Сокман автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, сынык сызык ясап, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,6 км кибеп баручы Заводской Лог инешенә кадәр бара, шушы инеш агымы буйлап аска таба 1,2 км аның башка кибеп баручы инеш белән кушылган җиренә кадәр уза һәм шушы инеш агымы буенча өскә таба 700 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 350 м һәм, урман массивын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км уза, сынык сызык ясап, Нәҗәр елгасын кисеп үтеп, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әгерҗе участок урманчылыгындагы 94 нче урман кварталының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буенча 400 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 94 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча 50 м бара, аннары урман массивы буйлап көньяк-көнбатышка

таба 300 м Сарсак-Умга, Тирсә һәм Яңа Бәзәкә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Вольный Труд поселогыннан 1,4 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сарсак-Умга авыл җирлеге чиге Яңа Бәзәкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Сарсак-Умга, Яңа Бәзәкә һәм Тәбәрле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Никольский поселогыннан 1,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 1,0 км буага кадәр уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, буа плотинасын кисеп үтеп, буа буйлап көнчыгышка таба 100 м Нәҗәр елгасына кадәр бара, аннары шушы елга агымы буенча аска таба 300 м уза, шуннан соң, Нәҗәр елгасының текә уңъяк ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 150 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 700 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 550 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м кибеп баручы Коробейников инешенә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча аска таба 1,2 км бара, шуннан соң «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әгерҗе участок урманчылыгындагы 143 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 550 м һәм, урман массивын һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 400 м 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сарсак-Умга авыл җирлеге чиге Тәбәрле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып урман полосасы буйлап төньяк-көнбатышка таба 500 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 300 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасы буенча 1,0 км, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м Яль-Пак елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча аска таба 1,1 км бара, шуннан соң, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 550 м, агач-куак массивы буйлап 250 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 150 м һәм төньяк-көнбатышка таба 100 м Чаж елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буйлап өскә таба 1,2 км уза, шуннан соң, Тирсә – Сокман автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әгерҗе участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 250 м, көнбатыш чиге буйлап

төньяк-көнчыгышка таба 450 м һәм төньяк-көнбатышка таба 500 м бара, аннары 89 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 1,6 км уза, аннары, сынык сызык ясап, 89, 88, 87 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,6 км бара, аннары 87 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 950 м бара, шуннан соң 83 нче, 82 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,4 км Сарсак-Умга, Тәбәрле авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Сарсак-Әрәмә авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Сарсак-Умга авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 9 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>20 нче кушымта

## Әгерҗе муниципаль районының «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Эсләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Эсләк авыл җирлеге Девәтернә, Кадыбаш авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Иске Эсләк авыл җирлеге чиге Девәтернә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Эсләк, Девәтернә авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Нарат авылыннан 1,9 км төньяк-көнчыгышта Кырыкмас елгасында урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып Кырыкмас елгасы агымы буенча аска таба 1,1 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 450 м, «Әгерҗе урманчылыгы» Татар-

стан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Девәтернә участок урманчылыгындагы 60 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча 1,1 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 60 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча 200 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км, көньяк-көнбатышка таба 3,6 км, урман массивын кисеп үтеп, төньяк-көнбатышка таба 950 м Девәтернә, Иске Эсләк һәм Кадыбаш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Эсләк авылыннан 2,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Эсләк авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Иске Эсләк, Кадыбаш авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Эсләк авылыннан 1,6 км төньяк-көнчыгышта Бима елгасында урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Эсләк авыл җирлеге чиге Кадыбаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 46 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 50 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 1,2 км, Иске Эсләк һәм Девәтернә авылларын тоташтыра торган профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасы буенча 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м кибеп баручы инешнең тамагына кадәр уза, шушы инеш агымы буенча аска таба 800 м бара, шуннан соң, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 600 м, урман массивы буенча 150 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, урман полосасы буенча 2,6 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,7 км, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 1,1 км, «Әгерҗе – Красный Бор» – Исәнбай – Иске Эсләк – Черново автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буенча 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, агач-куак массивы буенча 150 м, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Девәтернә участок урманчылыгындагы 63 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Чекалда авыл җирлеге Азево, Бима, Кадрәк, Салагыш, Шаршады авыл җирлекләре белән чиктәш.

Иске Чекалда авыл җирлеге чиге Кадрәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Чекалда, Кадрәк һәм Бима авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Чекалда авылыннан 700 м төньякта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнбатышка таба 2,2 км, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 1,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 1,1 км уза, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,0 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка таба 100 м уза, шуннан соң урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 650 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 143 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 45 нче, 59 нчы урман кварталларының

көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 1,5 км уза, шуннан соң, кибеп баручы инешләрне һәм Чекалда елгасын кисеп үтеп, 59 нчы, 58 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 1,1 км бара, аннары Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буенча төньяк-көнбатышка 1,5 км, 56 нчы урман кварталы буйлап 100 м уза, шуннан соң шушы урман кварталының төньяк чиге буенча көнбатышка таба 100 м, Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап 450 м бара, аннары, Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 100 м, 56 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м Иске Чекалда, Кадрәк һәм Шаршады авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сәхрә авылыннан 3,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чекалда авыл җирлеге чиге Бима авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Чекалда, Бима һәм Азево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Чекалда авылыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасыннан алып, «Әгерҗе – Красный Бор» – Исәнбай – Иске Эсләк – Черново автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньякка таба 200 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 900 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 250 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 1,0 км, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Красный Бор участок урманчылыгындагы 154 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 150 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 600 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 400 м уза, аннары урман массивының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнбатышка таба 300 м, төньяк-көнчыгышка таба 50 м, көньяк-көнчыгышка таба 350 м, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 950 м, көньяк-көнчыгышка таба 300 м, төньяк-көнбатышка таба 200 м, көньяк-көнчыгышка таба 250 м, төньяк-көнбатышка таба 700 м 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чекалда авыл җирлеге чиге Азево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Чекалда, Азево һәм Салагыш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Саклау авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюд-

жет учреждениесенең Красный Бор участок урманчылыгындагы 17 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, 17, 18, 9 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,5 км уза, шуннан соң «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 144 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча төньякка таба 100 м һәм төньяк чиге буйлап көнбатышка таба 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м уза, аннары «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Красный Бор участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 750 м, төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 650 м, төньяк чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м Чушкан елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча өскә таба 700 м уза, шуннан соң 6 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көнчыгышка таба 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, сынык сызык ясап, Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 9 нчы, 10 нчы урман кварталларының төньяк чиге буйлап 1,8 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча төньяк-көнчыгышка таба 200 м һәм 11 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 850 м 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чекалда авыл җирлеге чиге Салагыш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Чекалда, Салагыш һәм Шаршады авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Саклау авылыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып Чушкан елгасы агымы буенча өскә таба 500 м шушы елгага инеш койган җиргә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буйлап өскә таба 1,2 км аның тамагына кадәр бара, аннары, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнчыгышка таба 300 м уза, шуннан соң агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 100 м, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 155 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 300 м, «Әгерҗе – Красный Бор» – Салагыш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

150 м бара, аннары «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Красный Бор участок урманчылыгындагы 23 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Чекалда авыл җирлеге чиге Шаршады авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 125 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 500 м һәм төньяк чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 400 м уза, шуннан соң 124 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 250 м бара, 113 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 200 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 550 м уза, аннары, Чилчә елгасын кисеп үтеп, 113 нче, 95 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,5 км бара, шуннан соң, яңадан Чилчә елгасын кисеп үтеп, 95 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 600 м уза, аннары, инешләрне кисеп үтеп, 95 нче, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км бара, 85 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 250 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буйлап өскә таба 500 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 76 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 1,2 км уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 76, 71, 56 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,1 км 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>22 нче кушымта

## Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын

(«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Тәбәрле авыл җирлеге Яңа Бәзәкә, Сарсак-Умга авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Тәбәрле авыл җирлеге чиге Сарсак-Умга авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тәбәрле, Сарсак-Умга һәм Яңа Бәзәкә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Никольский поселогыннан 1,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасыннан алып урман полосасы буйлап төньяк-көнбатышка таба 500 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буенча 300 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасы буенча 1,0 км, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м Яль-Пак елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча аска таба 1,1 км бара, шуннан соң, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнбатышка таба 550 м, агач-куак массивы буйлап 250 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 150 м һәм төньяк-көнбатышка таба 100 м Чаж елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буйлап өскә таба 1,2 км уза, шуннан соң, Тирсә – Сокман автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әгерҗе участок урманчылыгындагы 85 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 250 м, көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 450 м һәм төньяк-көнбатышка таба 500 м бара, аннары 89 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 1,6 км уза, аннары, сынык сызык ясап, 89, 88, 87 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,6 км бара, аннары 87 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 950 м бара, шуннан соң 83 нче, 82 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,4 км Тәбәрле, Сарсак-Умга авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Сарсак-Әрәмә авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Тәбәрле авыл җирлеге чиге Яңа Бәзәкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тәбәрле, Яңа Бәзәкә авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Мукшур авылыннан 3,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 14 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең

Әгерҗе участок урманчылыгындагы 110 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 900 м, көнбатыш чиге буенча төньякка таба 300 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 110 нчы, 111 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап көнчыгышка таба 1,3 км бара, аннары, сынык сызык ясап, 109 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнчыгышка таба 1,4 км уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 109 нчы, 114 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 2,1 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көнчыгышка таба 150 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буйлап аска таба 650 м бара, шуннан соң урман полосасының көньяк чиге буенча көнчыгышка таба 2,0 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 350 м, 142 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буенча 150 м бара, шуннан соң, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньякка таба 900 м, урман массивын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 550 м, көньяк-көнчыгышка таба 150 м, Зур Варкләд елгасын һәм урман массивын кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 550 м уза, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 2,1 км, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м кибеп баручы инешкә кадәр, 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Тәбәрле авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 14 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>23 нче кушымта

## Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын

(«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Тирсә авыл җирлеге Кодаш, Көчек, Яңа Бәзәкә, Сарсак-Умга авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Тирсә авыл җирлеге чиге Кодаш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тирсә, Кодаш авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Иж-Бәйки авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта Иж елгасында урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып Иж елгасы буенча көнбатышка таба 30 м аның уңъяк ярына кадәр, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әгерҗе участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 150 м уза, шуннан соң, Черный күлен һәм Мувижа елгасын кисеп үтеп, 67, 66, 65, 64, 63, 62 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 3,9 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 400 м һәм көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 300 м бара, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 200 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасы буйлап 50 м һәм төньяк-көнбатышка таба 30 м уза, шушы урман полосасының көнчыгыш чиге буенча 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м бара, аннары 61 нче урман кварталының көньяк чиге буенча көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 60 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап көньякка таба 300 м, көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 500 м бара, аннары 68 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 800 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны ике мәртәбә кисеп үтеп, көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 100 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка таба 250 м бара, аннары агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 150 м, агач-куак массивы буенча 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буенча өскә таба 1,1 км бара, шуннан соң, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 200 м, Юринка елга-

сын кисеп үтеп, агач-куак массивы буенча 400 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньякка таба 200 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буенча 1,0 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буенча 650 м, Чаж елгасын, агач-куак һәм урман массивларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км Тирсә, Кодаш һәм Сарсак-Умга авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сарсак-Умга авылыннан 950 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Тирсә авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 6 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Тирсә, Көчек авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Рус Шаршадысы авылыннан 2,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тирсә авыл җирлеге чиге Көчек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тирсә, Көчек һәм Яңа Бәзәкә авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Вольный Труд поселогыннан 2,3 км көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып, Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, канауны һәм Иж елгасының текә уңъяк ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көнчыгышка таба 1,6 км Иж елгасына кадәр уза, шушы елга агымы буенча аска таба 1,6 км бара, аннары агач-куак массивы буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тирсә авыл җирлеге чиге Яңа Бәзәкә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тирсә, Яңа Бәзәкә һәм Сарсак-Умга авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Вольный Труд поселогыннан 1,4 км төньякта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км, «Әгерҗе – Красный Бор» – Яңавыл – Яңа Бәзәкә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 50 м һәм көньяк-көнбатышка таба 50 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әгерҗе участок урманчылыгындагы 100 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап көнчыгышка таба 750 м, төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 500 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 500 м һәм, берничә мәртәбә кибеп ба-

ручы инешне кисеп үтеп, көнчыгышка таба 700 м 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тирсә авыл җирлеге чиге Сарсак-Умга авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 250 м, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 100 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнбатышка таба 100 м, Тирсә – Сокман автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, сынык сызык ясап, шушы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,6 км кибеп баручы Заводской Лог инешенә кадәр бара, шушы инеш агымы буйлап аска таба 1,2 км аның башка кибеп баручы инеш белән кушылган җиренә кадәр уза һәм шушы инеш агымы буенча өскә таба 700 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 350 м һәм, урман массивын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км уза, сынык сызык ясап, Нәҗәр елгасын кисеп үтеп, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Әгерҗе участок урманчылыгындагы 94 нче урман кварталының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буенча 400 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 94 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча 50 м бара, аннары урман массивы буйлап көньяк-көнбатышка таба 300 м 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
24 нче кушымта

## Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре

чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Шаршады авыл җирлеге Кадрәк, Кичкетаң, Кырынды, Көчек, Салагыш, Иске Чекалда авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

Шаршады авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Шаршады, Көчек авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Кадрәк авылыннан 5,1 км төньяк-көнбатышта Кырыкмас елгасында урнашкан 16 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Шаршады, Кадрәк авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Кадрәк авылыннан 2,9 км көньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Шаршады авыл җирлеге чиге Кадрәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шаршады, Кадрәк һәм Иске Чекалда авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Сәхрә авылыннан 3,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 20 нче тоташу ноктасыннан алып «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка 400 м бара, сынык сызык ясап, төньякка таба 500 м, көнчыгышка таба 300 м, Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, төньякка таба 30 м уза, шуннан соң 43 нче урман кварталының көньяк чиге буенча көнбатышка таба 850 м, төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 450 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 200 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 300 м, 154 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м, агач-куак массивы буенча 50 м уза, 154 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буенча 150 м һәм 154 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м 19 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Шаршады авыл җирлеге чиге Иске Чекалда авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шаршады, Иске Чекалда һәм Салагыш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Саклау авылыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта Чушкан елгасында урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 125 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 500 м һәм төньяк чиге буенча төньяк-көнбатышка таба

400 м уза, шуннан соң 124 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 250 м бара, 113 нче урман кварталының көньяк чиге буенча 200 м һәм көньяк-көнчыгышка таба 550 м уза, аннары, Чилчә елгасын кисеп үтеп, 113 нче, 95 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,5 км бара, шуннан соң, яңадан Чилчә елгасын кисеп үтеп, 95 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 600 м уза, аннары, инешләрне кисеп үтеп, 95 нче, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км бара, 85 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 250 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, шушы инеш агымы буйлап өскә таба 500 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 76 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буенча төньяк-көнбатышка таба 1,2 км уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 76, 71, 56 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап төньяк-көнчыгышка таба 2,1 км 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Шаршады авыл җирлеге чиге Салагыш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шаршады, Салагыш һәм Кичкетаң авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Чилчәсе авылыннан 1,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче тоташу ноктасыннан алып «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 138, 139, 140 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 3,0 км уза, шуннан соң 133 нче, 125 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буенча 550 м төньяк-көнчыгышка таба Чушкан елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буйлап өскә таба 1,1 км 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шаршады авыл җирлеге чиге Кичкетаң авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шаршады, Кичкетаң һәм Кырынды авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Балтач авылыннан 3,6 км төньяк-көнчыгышта Иж елгасы акваториясендә урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып Иж елгасы буенча көньяк-көнчыгышка таба 40 м аның сулъяк ярына кадәр, агач-куак массивы буйлап 100 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 147 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 300 м, сынык сызык ясап, 850 м һәм 101 нче урман кварталы буйлап көньякка таба 50 м бара, аннары шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге

буенча төньяк-көнчыгышка таба 400 м, көнчыгыш чиге буйлап төньякка таба 250 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 102 нче, 103 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнчыгышка таба 2,6 км бара, аннары 103 нче, 93 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,1 км уза, шуннан соң, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буенча көньяк-көнчыгышка таба 1,5 км, 152 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м бара, аннары 104 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 500 м уза, 147 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, 104 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча 500 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 800 м уза, шуннан соң 105 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 20 м бара, аннары 112 нче, 111 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 1,2 км уза, шуннан соң 111 нче урман кварталы буенча көньяк-көнчыгышка таба 200 м һәм көнбатышка таба 150 м бара, сынык сызык ясап, шушы урман кварталының төньяк чиге буйлап 900 м бара, аннары, Чилчә елгасын кисеп үтеп, 111, 122, 131 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча көньяк-көнбатышка таба 2,7 км 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Шаршады авыл җирлеге чиге Кырынды авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Шаршады, Кырынды һәм Көчек авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чишмә авылыннан 3,6 км төньяк-көнчыгышта Иж елгасы акваториясендә урнашкан X = 516559,77, Y = 2360519,63 координаталы 17 нче тоташу ноктасыннан алып, Әгерҗе – Красный Бор автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Иж елгасы агымы буенча аска таба 13,3 км 26 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Шаршады авыл җирлеге чиге Көчек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 16 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, Кырыкмас елгасын һәм «Әгерҗе урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Шаршады участок урманчылыгындагы 145 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеген кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнбатышка таба 1,0 км, 16 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, Кырыкмас елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м уза, сазлыкны кисеп үтеп, 16 нчы, 15 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап көнбатышка таба 2,0 км бара, аннары 18 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап көньяк-көнбатышка

таба 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м уза, сазлыкны кисеп үтеп, 18 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,3 км Иж елгасына кадәр, 17 нче тоташу ноктасына кадәр бара.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 22 ноябре
№ 104-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1207. «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (IV өлеш); 2008, № 11 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), 2 – 22 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

## «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Минзәлә муниципаль районы Әгерҗе, Тукай, Сарман, Мөслим, Актаныш муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Минзәлә, Тукай һәм Әгерҗе муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Гөлек авылыннан 12,7 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (67 нче) тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 11,5 км көньяк-көнбатышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча, 2,4 км төньяк-көнбатышка таба сусаклагычның яр сызыгы буйлап уза, алга таба 100 м көнбатышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 185 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнбатышка таба 179 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 750 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба Игәт елгасына кадәр бара, бу елга агымы буенча 2,7 км өскә таба уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 2,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш

чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тиргәвеш елгасына кадәр бара, аннары бу елга агымы буенча 1,2 км өскә таба буага кадәр уза, 200 м буа буенча бара, кабат Тиргәвеш елгасы агымы буенча 3,7 км өскә таба, Минзәлә — Боерган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, буага кадәр, 200 м буа буенча бара, Тиргәвеш елгасы агымы буенча 750 м өскә таба буага кадәр, 450 м буа буенча, кабат Тиргәвеш елгасы агымы буенча 3,2 км өскә таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 3,1 км көньякка таба, инешнең текә ярларын һәм инешнең үзен кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 900 м көньяк-көнбатышка таба 97 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 900 м төньяк-көнбатышка таба 96 нчы урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 2,2 км көньяк-көнбатышка таба 96 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба 96 нчы урман кварталының көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап уза, алга таба 150 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 650 м көнчыгышка таба 96 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары 300 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 600 м көнчыгышка таба 96 нчы, 97 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 97 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сынык сызык ясап, 950 м төньяк-көнчыгышка таба 97 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 97 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 100 м, сынык сызык ясап, 200 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 3,1 км көньяк-көнбатышка таба 98, 103, 107, 109, 111 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, 200 м төньяк-көнбатышка таба 113 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, 183 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, алга таба 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көньяк-көнбатышка таба 550 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 1,0 км көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары

182 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 950 м, урман массивы буйлап 50 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан участок урманчылыгындагы 121 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 100 м һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м уза, алга таба 108 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 850 м һәм, сынык сызык ясап, 1,0 км көнбатышка таба бара, аннары 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, алга таба 1,2 км, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 182 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, 93 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 1,2 км уза, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 93, 94, 95 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, инеш һәм Борылык елгасын кисеп үтеп, 1,3 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, Борылык елгасын кабат кисеп үтеп, 50 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары «Алабуга урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, алга таба 55 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м бара, аннары 300 м төньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 500 м һәм, сынык сызык ясап, 1,1 км көньякка таба 56 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, көньяк-көнчыгышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 800 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, ан-

нары 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, берничә киптерү канавын, инешләрне кисеп үтеп, Буклы елгасына кадәр уза, алга таба бу елга агымы буенча 6,7 км аска таба, «Мәскәү — Уфа» — Хуҗамәт — Иске Абдул автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аның Оргыды елгасына койган җиренә кадәр бара, бу елга агымы буенча 650 м өскә таба уза, аннары 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, инешне һәм «Минзәлә — Рус Караны — Тугаш» — Хуҗамәт автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 5,1 км көньяк-көнбатышка таба уза, алга таба 4,3 км көньяк-көнчыгышка таба Игәнә елгасына кадәр бара, бу елга агымы буенча 600 м өскә таба уза, көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м бара, аннары 2,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Минзәлә, Тукай һәм Сарман муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шикәрле Каен авылыннан 4,1 км көньякта урнашкан 31 нче (68 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 31 нче (68 нче) тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көньяк-көнчыгышка таба, 2,5 км төньяк-көнчыгышка таба, 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба уза, агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Зур Нөркәй — Кадрәк автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 3,6 км төньяк-көнчыгышка таба Минзәлә елгасын һәм аның текә уң ярын кисеп үтеп уза, 3,2 км көньяк-көнчыгышка таба Минзәлә, Сарман һәм Мөслим муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Иске Мунча авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче (69 нчы) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 33 нче (69 нчы) тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

кибеп баручы Шарлык инешенә кадәр уза, инеш агымы буенча 850 м аска таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м төньяк-көнчыгышка таба, 2,8 км көньяк-көнчыгышка таба, Шарлык инешен һәм кибеп баручы исемсез инешне кисеп үтеп, Сөрәнчәк елгасына кадәр, бу елга агымы буенча 2,5 км өскә таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,4 км көньяк-көнчыгышка таба һәм 2,2 км төньяк-көнчыгышка таба уза, 600 м көньякка таба Минзәлә – Рус Караны – Тугаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 40 м көньяк-көнчыгышка таба агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 2,7 км өскә таба уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м көньякка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м үзәнлектәге сазлык буенча, 250 м үзәнлектәге сазлыкның төньяк чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м үзәнлектәге сазлык буенча, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 1,0 км урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Ык елгасына кадәр уза, алга таба 850 м төньяк-көнчыгышка таба бу елганың сул яры буйлап, 20 м көньяк-көнчыгышка таба Ык елгасы буйлап бара һәм бу елга агымы буенча 3,9 км аска таба, 2,2 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба агач-куак массивы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 150 м бара, аннары, сынык сызык ясап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, алга таба бу инеш агымы буенча 500 м аска таба күлгә кадәр, 100 м күлнең көнчыгыш яры буйлап, кабат кибеп баручы инеш агымы буенча 150 м аска таба күлгә кадәр, 50 м күл буенча, кибеп баручы инеш агымы буенча 100 м аска таба күлгә кадәр, 200 м күлнең төньяк-көнбатыш яры буйлап, кибеп баручы инеш агымы буенча 800 м аска таба аның Ык елгасына койган җиренә кадәр бара, бу елга агымы буенча 1,3 км аска таба уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба, күлне кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м үзәнлектәге сазлык буенча, 50 м агач-куак массивының төньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 350 м үзәнлектәге сазлык буенча, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,0 км көньяк-көнбатышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Калинин участок урманчылыгындагы 31 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 1,2 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, күлгә кадәр, 1,7 км көньякка таба

күл буйлап, кибеп баручы инеш агымы буенча 750 м аска таба бара, 50 м көньяк-көнчыгышка таба агач-куак массивы буйлап, 50 м көньяк-көнбатышка таба агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап, 150 м көньякка таба һәм 200 м төньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мөслим участок урманчылыгындагы 103 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, 100 м урман массивының көньяк чиге буйлап, 500 м үзәнлектәге сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 950 м көньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Калинин участок урманчылыгындагы 31 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 400 м көньяк-көнбатышка таба 98 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап, 200 м үзәнлектәге сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 50 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м 98 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба, сынык сызык ясап, 1,7 км көнчыгышка таба 35 нче, 36 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м төньяк-көнчыгышка таба бара, сынык сызык ясап, 2,7 км көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Мөслим участок урманчылыгындагы 45, 46, 47 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, 500 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 650 м көньяк-көнчыгышка таба бара, 750 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,0 км көньяк-көнбатышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба уза, аннары урман утыртмаларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, инешнең текә ярын кисеп үтеп, Ташъелга инешенә кадәр уза, алга таба бу инеш агымы буенча 1,9 км өскә таба, 50 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 850 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап, Филимоновка һәм Ташъелга авылларын тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнчыгышка таба 54 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Калинин учас-

ток урманчылыгындагы 102 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, аннары 102 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, сынык сызык ясап, 150 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Карал-Шат инешенең чишмә башына кадәр уза, бу инеш агымы буенча 5,2 км аска таба, 550 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 100 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Карал-Шат инешенә кадәр уза, алга таба бу инеш агымы буенча 1,4 км аска таба, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнчыгышка таба буа буенча, көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,5 км бара, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Озын Күпер инешенә кадәр 350 м бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, Озын Күпер инешен, киптерү канауларын һәм чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км, торф чыгару урынының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, алга таба 101 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, Мөшеге елгасының текә ярын кисеп үтә, Озын Күпер инеше агымы буенча 3,9 км өскә таба, төньяк-көнчыгышка таба 10 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап кибеп баручы Баҗана елгасының чишмә башына кадәр бара, аннары бу елга агымы буенча 1,5 км аска таба, 50 м төньяк-көнбатышка таба яр буе агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, текә ярны кисеп үтә, урман утыртмаларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, алга таба 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Минзәлә, Мөслим һәм Актаныш муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Рус Мөшегесе авылыннан 4,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче (70 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге

белән чиктәш җирдә Минзәлә, Актаныш муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Сарсазтау авылыннан 17,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 17 нче (19 нчы) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 100 м, агач-куак массивы буйлап 50 м, үзәнлектәге сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, үзәнлектәге сазлыкның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, агач-куак полосасын кисеп үтеп, 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак полосасын һәм сазлыкны кисеп үтеп, 250 м, үзәнлектәге сазлык буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 500 м, Камышлы күле буенча 150 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 350 м, Кәкрекүл күле буенча 100 м, үзәнлектәге сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 750 м көньякка таба, агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 300 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, агач-куак массивы буйлап 250 м уза, алга таба 250 м төньяк-көнчыгышка таба Каракүл күленең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,0 км төньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 342 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары 200 м көньяк-көнчыгышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба, 200 м көньяк-көнчыгышка таба әлеге урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 350 м агач-куак массивы буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 400 м, көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, агач-куак массивы буйлап 50 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 50 м, агач-куак массивы буйлап 50 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 50 м, агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап 50 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 200 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 1,4 км һәм көньяк-көнбатышка таба 400 м бара, агач-куак массивы буйлап 150 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 250 м, агач-куак массивы буйлап 650 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 200 м, агач-куак массивы буйлап 150 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 400 м, агач-куак массивы буйлап 800 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 250 м, агач-куак массивының көньяк чиге буйлап 50 м, агач-куак массивы буйлап 50 м уза, аннары бу урманчылыктагы 62, 61, 60, 59 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,9 км һәм 365 нче, 366 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 1,1 км, сынык сызык ясап,

көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км, агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, агач-куак массивы буйлап 50 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, 5,2 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 200 м төньяк-көнчыгышка таба урман массивының төньяк чиге буйлап, 100 м урман массивының көньяк чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының төньяк чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м урман массивы буйлап, 200 м урман массивының көньяк чиге буйлап, 700 м урман массивы буйлап, 600 м урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 800 м урман массивы буйлап, 750 м төньяк-көнчыгышка таба 465 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 465 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м көньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба уза, алга таба үзәнлектәге сазлык буйлап 1,4 км, әлеге урманчылыктагы 465 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, 460, 461, 464 нче урман кварталлары буйлап 2,4 км, төньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актаныш участок урманчылыгындагы 358 нче урман кварталы буйлап 1,8 км, бу урманчылыктагы 358 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 3,3 км, 358 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Бөгә елгасына кадәр 1,0 км бара, аннары бу елганың сул яры буйлап аның агымы буенча 200 м аска таба, сынык сызык ясап, 1,8 км көнбатышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 463 нче, 462 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап Бөгә елгасына кадәр уза, алга таба елга агымы буенча 2,6 км аска таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап, 50 м үзәнлектәге сазлык буйлап бара, аннары урман массивы буйлап 400 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 100 м, агач-куак массивы буйлап 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, сынык сызык ясап, агач-куак массивы буйлап 550 м, көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак полосасын кисеп үтеп, 250 м, агач-куак массивы буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м уза, агач-куак полосасын кисеп үтә һәм үзәнлектәге сазлык буйлап 50 м, агач-куак массивы буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м,

үзәнлектәге сазлык буйлап Ык елгасына кадәр 100 м бара, аннары бу елга агымы буенча 750 м аска таба уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба үзәнлектәге сазлык буйлап 50 м, күл буенча 350 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 800 м бара, аннары 550 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак полосасын һәм үзәнлектәге сазлыкны кисеп үтеп, инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 150 м аска таба күлгә кадәр уза, аннары 450 м көньяк-көнчыгышка таба күл буенча, төньяк-көнчыгышка таба үзәнлектәге сазлык буйлап 50 м, агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба һәм 250 м көньяк-көнбатышка таба, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м бара, алга таба үзәнлектәге сазлык буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, алга таба күл буенча 50 м уза, аннары, сынык сызык ясап, агач-куак массивы буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, күл буенча 50 м, үзәнлектәге сазлык буйлап күлгә кадәр 350 м бара, алга таба әлеге күл буенча 150 м төньяк-көнчыгышка таба, үзәнлектәге сазлык буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба, агач-куак массивы буйлап Ык елгасына кадәр 500 м уза, алга таба бу елга агымы буенча 4,3 км өскә таба аның элеккеге үзәне тамагына кадәр бара, аннары Ык елгасының элеккеге үзәне буйлап күлне һәм Ык елгасының элеккеге үзәнен тоташтыручы ермакка кадәр 1,3 км уза, алга таба бу ермак буйлап күлгә кадәр 350 м бара, аннары күл буенча 400 м төньяк-көнчыгышка таба күлне Баҗана елгасы белән тоташтыручы ермакка кадәр уза, алга таба ермак буенча Баҗана елгасына кадәр 250 м уза, аннары бу елга агымы буенча 1,3 км өскә таба, үзәнлектәге сазлык буйлап 50 м бара, алга таба күл буенча 100 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 50 м, кабат күл буенча 150 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 50 м, агач-куак массивы буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км көньяк-көнчыгышка таба һәм, чокырны кисеп үтеп, 150 м төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кабат чокырны кисеп үтеп, 200 м бара, алга таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 850 м һәм көньяк-көнбатыш чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 1,0 км уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Урьяды елгасына кадәр 350 м бара, бу елга агымы буенча 1,2 км аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба агач-куак массивы буйлап Баҗана елгасына кадәр 1,7 км бара, алга таба бу елга

агымы буенча 7,1 км өскә таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, үзәнлектәге сазлык буйлап, күлне кисеп үтеп, 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м һәм көньяк-көнбатышка таба, күлне кисеп үтеп, 150 м уза, алга таба агач-куак массивы буйлап, Югары Ияс күлен кисеп үтеп, 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Каракаш күлен кисеп үтеп, 100 м, агач-куак массивы буйлап 100 м бара, аннары үзәнлектәге сазлык буйлап 150 м, агач-куак массивы буйлап 150 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 200 м уза, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, үзәнлектәге сазлык буйлап 200 м һәм көньяк-көнбатышка таба 50 м бара, аннары агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, агач-куак массивы буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м уза, алга таба агач-куак массивы буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, агач-куак массивы буйлап инешкә кадәр 250 м бара, аннары бу инеш агымы буенча 850 м аска таба күлгә кадәр, көньяк-көнбатышка таба күл буенча 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба уза, алга таба 400 м төньяк-көнбатышка таба, күлне кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба агач-куак массивы буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м һәм төньяк-көнбатышка таба 250 м, агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, агач-куак массивы буйлап, күлне кисеп үтеп, 100 м уза, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба агач-куак массивы буйлап күлгә кадәр 350 м бара, аннары күл буенча 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба, агач-куак массивы буйлап 100 м көньякка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, агач-куак массивы буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, агач-куак массивы буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, көньяк-көнбатышка таба агач-куак массивы буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап күлгә кадәр 400 м уза, алга таба 300 м көньяк-көнчыгышка таба күлнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м агач-куак массивы буйлап күлгә кадәр бара, аннары 1,4 км көньяк-көнбатышка таба күл буенча уза, алга таба күлдән чыгып агучы чишмә агымы буенча 150 м аска таба күлгә кадәр бара, шуннан соң 1,3 км көньякка таба әлеге күл буенча күлгә коючы инеш тамагына кадәр бара, аннары бу инеш агымы буенча 200 м өскә таба күлгә кадәр, төньяк-көнбатышка таба күл буенча 150 м, агач-куак массивы буйлап, Ык елгасының текә ярын кисеп үтеп, елгага кадәр 700 м уза, алга таба, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына

бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, бу елга агымы буенча 5,3 км өскә таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, сынык сызык ясап, 2,1 км көньяк-көнбатышка таба, 750 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнбатышка таба, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба, авыл хуҗалыгында кулланылмый торган җирләр буйлап 100 м, «Мәскәү – Уфа» – Иске Иркәнәш – Татар Мөшегесе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км көньяк-көнбатышка таба, 950 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба, «Мәскәү – Уфа» – Иске Иркәнәш – Татар Мөшегесе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,4 км, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Калинин участок урманчылыгындагы 16 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, инешләрне кисеп үтеп, 700 м, көньяк-көнчыгышка таба бу урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км уза, Яңа Айман һәм Пучы авылларын тоташтыручы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 20 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,9 км, сынык сызык ясап, 1,9 км көньяк-көнбатышка таба 20 нче, 19 нчы урман кварталларының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 600 м көньяк-көнбатышка таба, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба, агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, чокыр төбе буенча инешкә кадәр 100 м уза, алга таба бу инеш агымы буенча 1,6 км өскә таба буага кадәр, буа буенча 100 м, кабат инеш агымы буенча 550 м өскә таба, 39 нчы, 43 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,2 км көньякка таба, 44 нче, 47 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 900 м, төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм 450 м көньяк-көнчыгышка таба 25 нче (70 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә Минзәлә, Әгерҗе му-

ниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Сарсазтау авылыннан 15,2 км төньякта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 16(А) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап көнбатышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча 17 нче (19 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 16(А) тоташу ноктасыннан алып Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча 2,9 км көнбатышка таба, 4,1 км төньяк-көнбатышка таба, 350 м көнбатышка таба уза, алга таба кабат 900 м төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, берничә утрауны кисеп үтеп, 3,3 км көньяк-көнбатышка таба бара, сынык сызык ясап, берничә утрауны кисеп үтеп, 7,9 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба, 700 м төньяк-көнбатышка таба, 650 м көньяк-көнбатышка таба уза, алга таба, сынык сызык ясап, берничә утрауны кисеп үтеп, 1,6 км төньяк-көнбатышка таба, берничә утрауны кисеп үтеп, 350 м төньякка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, берничә утрауны кисеп үтеп, 2,3 км төньяк-көнбатышка таба, 700 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 700 м төньяк-көнбатышка таба 1 нче (67 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы»<br>
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы<br>
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре<br>
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»<br>
Татарстан Республикасы Законына<br>
3 нче кушымта

## Минзәлә муниципаль районының «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге Воровский, Тауасты Байлар, Иске Мәҗын, Ырыс, Юртово авыл җирлекләре, Әгерҗе, Актаныш муниципаль районнары һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Әгерҗе муниципаль районы белән чиктәш җирдә «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Ырыс авыл җирлеге һәм Әгерҗе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Гөлек авылыннан 11,2 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 2 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Әгерҗе муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Сарсазтау авылыннан 15,2 км төньякта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 16(А) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 16(А) тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба Татарстан Республикасы административ чиге буйлап «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Актаныш муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Сарсазтау авылыннан 17,5 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 17 нче (19 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Актаныш муниципаль районы белән чиктәш җирдә 17 нче (19 нчы) тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Воровский авыл җирлеге һәм Актаныш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Дусай-Кичү авылыннан 6,2 км төньякта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=472925,47, Y=2383702,79 координаталы 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Воровский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Воровский һәм Иске Мaҗын авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Воровский ис. совхоз поселогыннан 2,4 км көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=467602,19, Y=2368637,23 координаталы 14 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 4,5 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 100 м сазлык буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 700 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 200 м сазлык буенча, 200 м агач-куак массивы буйлап, 100 м күлнең көнчыгыш чиге буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 150 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 200 м сазлык буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 250 м агач-куак массивы буйлап, 50 м сазлык буенча, 100 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сазлыкны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, 450 м Түбән Кама сусаклагычы аква-

ториясе буйлап, 550 м агач-куак массивы буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м сазлык буенча, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 450 м сазлык буенча, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 1,8 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 150 м агач-куак массивы буйлап, 750 м күл буенча, агач-куак массивын кисеп үтеп, 150 м сазлык буенча, 50 м күл буенча, берничә тапкыр сазлыкны кисеп үтеп, 250 м агач-куак массивы буйлап, 400 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буенча, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 750 м агач-куак массивы буйлап, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буенча, 150 м сазлык буенча, 250 м агач-куак массивы буйлап, 200 м сазлык буенча, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Иске Маҗын авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Иске Маҗын һәм Юртово авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Юртово поселогыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 950 м сазлык буенча, агач-куак полосасын һәм дамбаны кисеп үтеп, 1,5 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Юртово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Юртово һәм Тауасты Байлар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Юртово поселогыннан 2,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба Минзәлә — Боерган автомобиль юлы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба 2,2 км көньяк-көнбатышка таба Минзәлә шәһәрен әйләнеп үтүче автомобиль юлы буйлап уза, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлы буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Тауасты Байлар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Минзәлә шәһәре» муни-

ципаль берәмлеге, Тауасты Байлар һәм Ырыс авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тауасты Байлар авылыннан 3,7 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 1,0 км сусаклагычның сул ярына кадәр, яр буе комлыгы буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 151 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм, ике тапкыр чокырларны кисеп үтеп, 250 м көнчыгышка таба, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 300 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км урман полосасы буйлап уза, көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, 149 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 149 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Ырыс авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба, берничә тапкыр агач-куак массивын, сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, 2,6 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м агач-куак массивы буйлап, 200 м сазлык буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 550 м агач-куак массивы буйлап, 150 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 350 м агач-куак массивы буйлап, 100 м сазлык буенча, 150 м күл буенча, 150 м агач-куак массивы буйлап, 150 м күл буенча, ике тапкыр сазлыкны кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап, 50 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 450 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м агач-куак массивы буйлап, 150 м сазлык буенча, 600 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 200 м сазлык буенча, 150 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, 200 м сазлык буенча, 500 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 300 м сазлык буенча, 200 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 150 м сазлык буенча, 300 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап,

200 м сазлык буенча, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 200 м сазлык буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 450 м агач-куак массивы буйлап, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 150 м агач-куак массивы буйлап, 300 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны, агач-куак массивын һәм полосасын кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,5 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Минзәлә муниципаль районының «Әтрәкле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Әтрәкле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Әтрәкле авыл җирлеге Иркәнәш авыл җирлеге, Актаныш һәм Мөслим муниципаль районнары белән чиктәш.

Әтрәкле авыл җирлеге чиге Актаныш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Әтрәкле, Иркәнәш авыл җирлекләре һәм Актаныш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яту авылыннан 1,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап Әтрәкле авыл җирлеге, Актаныш һәм Мөслим муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Рус Мөшегесе авылыннан 4,1 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 25 нче (70 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Әтрәкле авыл җирлеге чиге Мөслим муниципаль районы белән чиктәш җирдә 25 нче (70 нче) тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап Әтрәкле, Иркәнәш авыл җирлекләре һәм Мөслим муниципаль районы чикләре тоташкан урында Калтак авылыннан 2,5 км көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Әтрәкле авыл җирлеге чиге Иркәнәш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 3,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Иске Иркәнәш – Татар Мөшегесе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 1,5 км төньяк-көнбатышка таба, 400 м дамбаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 10 м урман полосасы буйлап уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 300 м урман полосасы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, текә ярларны, чокырны, агач-куак массивын һәм Мөшеге елгасын берничә тапкыр кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Калинин участок урманчылыгындагы 100 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба төньяк-көнбатышка таба 20 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м урман полосасы буйлап, 100 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 99 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, агач-куак массивын һәм урман массивын кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м, чокырны кисеп үтеп, 97 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м 98 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 750 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта

**Минзәлә муниципаль районының «Аю авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Аю авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Аю авыл җирлеге Бикбау, Воровский, Николаевка, Яңа Мәлкән, Иске Маҗын һәм Иске Матвеевка авыл җирлекләре белән чиктәш.

Аю авыл җирлеге чиге Яңа Мәлкән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аю, Яңа Мәлкән һәм Бикбау авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Куян авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 4,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, кибеп баручы инеш агымы буенча 650 м өскә таба бара, аннары 600 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 2,6 км көньяк-көнбатышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 113, 115, 114 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 700 м төньяк-көнбатышка таба 114 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 700 м көньяк-көнчыгышка таба, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 116 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 116 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,4 км төньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба, Мәскәү –

Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 116, 114, 110 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 107 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба уза, ике тапкыр Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба һәм 50 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 200 м төньякка таба 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 50 м Аю, Яңа Мәлкән һәм Воровский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дружба авылыннан 650 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Аю авыл җирлеге чиге Бикбау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, Брустан елгасын һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба, Урта Ружевка һәм Әхмәт поселокларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнчыгышка таба, көньяк-көнбатышка таба 3,1 км, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чигенә кадәр, урман полосасын кисеп үтеп, Аю, Бикбау һәм Иске Матвеевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Аю авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Коноваловка авыл җирлеге чиге Кадрәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Коноваловка, Кадрәк һәм Наратлы Кичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Исәнгол авылыннан 2,7 км көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 197 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 180 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м төньяк-көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м көньякка таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 195 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 400 м уза, 1,7 км урман полосасы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап, 250 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньякка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м көньяк-көнчыгышка таба, 500 м төньяк-көнчыгышка таба, 500 м көньяк-көнчыгышка таба 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Коноваловка авыл җирлеге чиге Наратлы Кичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 30 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м төньяк-көнчыгышка таба,

1,3 км кабат төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 900 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, агач-куак массивын һәм Минзәлә елгасының текә уң ярын кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Коноваловка, Наратлы Кичү һәм Хуҗамәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Исәнгол авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта Минзәлә елгасында урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Коноваловка авыл җирлеге чиге Хуҗамәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә елгасы агымы буенча 1,4 км аска таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, Минзәлә елгасының текә сул ярын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 3,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м сазлык буенча, агач-куак массивын һәм Оргыды елгасын берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Оргыды елгасын һәм сазлыкны берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м агач-куак массивы буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 450 м агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м сазлык буенча уза, төньяк-көнбатышка таба 10 м сазлык буенча, Оргыды елгасын һәм канауны кисеп үтеп, 150 м агач-куак массивы буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибеп баручы инешне һәм агач-куак полосаларын кисеп үтеп, 3,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 117 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м һәм төньяк-көнбатышка таба 850 м уза, 106 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 600 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м, 102 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 50 м төньяк-көнбатышка таба уза, 102 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 1,4 км бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 101 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
12 нче кушымта

## Минзәлә муниципаль районының «Хуҗамәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Хуҗамәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Хуҗамәт авыл җирлеге Югары Тәкермән, Коноваловка, Наратлы Кичү, Ырыс авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы белән чиктәш.

Хуҗамәт авыл җирлеге чиге Ырыс авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Хуҗамәт, Ырыс авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бакчасарай авылыннан 2,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып 450 м көньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 97 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы Сөрмәт елгасына кадәр уза, бу елга агымы буенча 1,2 км аска таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 99 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 30 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 50 м, 99 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 400 м көнчыгышка таба, кибеп баручы Сөрмәт елгасын кисеп үтеп, 99 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 20 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 250 м көньяк-көнбатышка таба бара, 99 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 99 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м уза, аннары 100 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м

көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көньякка таба 100 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, алга таба 100 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Яңа Александровка – Тулыбай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 650 м бара, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба 101 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Хуҗамәт, Ырыс һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бакчасарай авылыннан 2,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Хуҗамәт авыл җирлеге чиге Коноваловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Хуҗамәт, Коноваловка һәм Наратлы Кичү авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Исәнгол авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта Минзәлә елгасында урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә елгасы агымы буенча 1,4 км аска таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, Минзәлә елгасының текә сул ярын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 3,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м сазлык буенча, агач-куак массивын һәм Оргыды елгасын берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Оргыды елгасын һәм сазлыкны берничә тапкыр кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м агач-куак массивы буйлап бара, алга таба көньяк-көнбатышка, сынык сызык ясап, 450 м агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м сазлык буенча уза, төньяк-көнбатышка таба 10 м сазлык буенча, Оргыды елгасын һәм канауны кисеп үтеп, 150 м агач-куак массивы буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, кибеп баручы инешне һәм агач-куак полосаларын кисеп үтеп, 3,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 117 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 900 м һәм төньяк-көнбатышка таба 850 м уза, 106 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 600 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка

таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м, 102 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 950 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 50 м төньяк-көнбатышка таба уза, 102 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 1,4 км бара, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 101 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Хуҗамәт авыл җирлеге чиге Наратлы Кичү авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә елгасы агымы буенча 100 м өскә таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м текә ярның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,3 км төньяк-көнбатышка таба Хуҗамәт, Наратлы Кичү авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Исәнгол авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Хуҗамәт авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап көньякта 10 нчы тоташу ноктасыннан алып Хуҗамәт, Югары Тәкермән авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Хуҗамәт авылыннан 1,6 км көньяк-көнбатышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасына кадәр, төньякта Хуҗамәт, Югары Тәкермән авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бакчасарай авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасыннан алып 7 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Хуҗамәт авыл җирлеге чиге Югары Тәкермән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,4 км «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 111, 113, 115 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м көньяк-көнчыгышка таба һәм, агач-куак массивын һәм инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 3,2 км көньяк-көнбатышка таба бара, Борылык елгасы агымы буенча 2,7 км өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 20 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын һәм Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының

көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Буклы елгасына кадәр, аның текә сул ярын кисеп үтеп, 9 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
13 нче кушымта

**Минзәлә муниципаль районының «Наратлы Кичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Наратлы Кичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Наратлы Кичү авыл җирлеге Кадрәк, Коноваловка, Хуҗамәт авыл җирлекләре, Сарман һәм Тукай муниципаль районнары белән чиктәш.

Наратлы Кичү авыл җирлеге чиге Хуҗамәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Наратлы Кичү, Хуҗамәт һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Исәнгол авылыннан 2,3 км төньяк-көнчыгышта Минзәлә елгасында урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә елгасы агымы буенча 100 м өскә таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м текә ярның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,3 км төньяк-көнбатышка таба Наратлы Кичү, Хуҗамәт авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Исәнгол авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Наратлы Кичү авыл җирлеге чиге Коноваловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Наратлы Кичү, Коноваловка һәм Кадрәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Исәнгол авылыннан 2,7 км көнчыгышта урнашкан 30 нчы тоташу нокта-

сыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, 1,3 км кабат төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 900 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, агач-куак массивын һәм Минзәлә елгасының текә уң ярын кисеп үтеп, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Наратлы Кичү авыл җирлеге чиге Кадрәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Наратлы Кичү, Кадрәк авыл җирлекләре һәм Сарман муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Тәкермән авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 32 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м төньяк-көнчыгышка таба, агач-куак массивын кисеп үтеп, 2,8 км кабат төньяк-көнбатышка таба, 350 м төньяк-көнчыгышка таба һәм, текә ярны һәм чокырны кисеп үтеп, 550 м көнчыгышка таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 100 м урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярларны, Кадрәк һәм Наратлы Кичү авылларын тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны берничә тапкыр кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, алга таба инеш агымы буенча 100 м аска таба аның Минзәлә елгасына койган урынына кадәр уза, бу елга агымы буенча 1,4 км аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешләрне берничә тапкыр кисеп үтеп, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,0 км төньяк-көнбатышка таба, 100 м агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Наратлы Кичү авыл җирлеге чиге Сарман муниципаль районы белән чиктәш җирдә 32 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап Наратлы Кичү авыл җирлеге, Сарман һәм Тукай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Шикәрле Каен авылыннан 4,1 км көньякта урнашкан 31 нче (68 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Наратлы Кичү авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 31 нче (68 нче) тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

**Минзәлә муниципаль районының «Николаевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Николаевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Николаевка авыл җирлеге Аю, Иркәнәш, Яңа Маҗын, Иске Маҗын, Иске Матвеевка, Юшады авыл җирлекләре һәм Мөслим муниципаль районы белән чиктәш.

Николаевка авыл җирлеге чиге Иске Маҗын авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Николаевка, Иске Маҗын һәм Юшады авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чулпан авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 77, 79, 83 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 3,1 км төньяк-көнчыгышка таба 84, 80, 70, 56 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 550 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 600 м төньяк-көнчыгышка таба 57 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап Николаевка, Иске Маҗын һәм Аю авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чулпан авылыннан 1,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Николаевка авыл җирлеге чиге Аю авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Николаевка, Аю һәм Иске Матвеевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Степановка авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасы буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Рес-

публикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 203 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба көньяк-көнчыгышка 68 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 50 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 68 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 350 м һәм көнчыгыш чиге буйлап 550 м уза, алга таба 69 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 500 м көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 400 м төньякка таба, төньяк чиге буйлап 450 м төньяк-көнбатышка таба бара, алга таба 450 м төньякка таба 68 нче, 67 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,8 км көнбатышка таба 67 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, алга таба 500 м төньяк-көнбатышка таба 66 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 350 м төньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 53 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, алга таба 400 м төньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 1,7 км төньяк-көнбатышка таба 53 нче, 52 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Брустан елгасына кадәр уза, Брустан елгасы агымы буенча 1,3 км өскә таба буага кадәр бара, 50 м көньяк-көнбатышка таба буаның уң яры буйлап уза, аннары инеш агымы буенча 350 м өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, алга таба бу кибеп баручы инеш агымы буенча 1,4 км өскә таба уза, көньякка таба 64 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 50 м, буаның уң яры буйлап 100 м бара, алга таба кибеп баручы инеш агымы буенча 700 м өскә таба бара, шуннан соң 300 м көньяк-көнбатышка таба 64 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 1,3 км көнбатышка таба 73 нче, 72 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, аннары 72 нче, 63 нче урман кварталларының төньяк һәм көнчыгыш чикләре буйлап 550 м төньякка таба бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 63 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 30 м уза, алга таба кибеп баручы инеш агымы буенча 850 м аска таба уза, сынык сызык ясап, 350 м төньякка таба 58 нче, 59 нчы урман кварталлары буйлап, 400 м төньяк-көнчыгышка таба 59 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, 59 нчы урман кварталы буй-

лап 100 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 1,9 км көнбатышка таба 59 нчы, 58 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, алга таба 950 м төньяк-көнбатышка таба 57 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Николаевка авыл җирлеге чиге Иске Матвеевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 41 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, Иске Матвеевка – Николаевка – Рус Караны автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Николаевка, Иске Матвеевка һәм Иркәнәш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Үртамак авылыннан 1,7 км көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Николаевка авыл җирлеге чиге Иркәнәш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Николаевка, Иркәнәш авыл җирлекләре һәм Мөслим муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Маҗын авылыннан 2,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнчыгышка таба сазлык буенча бара, алга таба, сынык сызык ясап, 1,8 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 150 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап, 150 м сазлыкның көнбатыш чиге буенча, 100 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап, 200 м сазлыкның көнбатыш чиге буенча, 50 м агач-куак массивының көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м төньяк-көнбатышка таба сазлыкның көнбатыш чиге буенча бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба һәм, агач-куак массивын, кибеп баручы инешне, канауны һәм профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба уза, агач-куак массивы буйлап, Каран елгасын кисеп үтеп, 500 м, агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м, агач-куак массивы буйлап 100 м бара, алга таба, сынык сызык ясап, 850 м төньяк-көнбатышка таба, сазлыкны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 200 м сазлык буенча уза, төньяк-көнчыгышка таба 50 м агач-

куак массивы буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буенча, инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м агач-куак массивы буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Николаевка авыл җирлеге чиге Мөслим муниципаль районы белән чиктәш җирдә 38 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап Николаевка, Яңа Маҗын авыл җирлекләре һәм Мөслим муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Маҗын авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Николаевка авыл җирлеге чиге Яңа Маҗын авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча 1,0 км өскә таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 50 м агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 50 м көньяк-көнбатышка таба агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап уза, төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлык буенча, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, канауны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 400 м көньяк-көнбатышка таба, канауны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 1,2 км сазлыкның көньяк чиге буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 1,0 км сазлыкның көньяк чиге буйлап уза, төньяк-көнбатышка таба, Минзәлә – Рус Караны – Тугаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Николаевка, Яңа Маҗын һәм Юшады авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Караны авылыннан 3,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Николаевка авыл җирлеге чиге Юшады авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,0 км

төньяк-көнбатышка таба, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба бара, 400 м көнчыгышка таба Минзәлә – Рус Караны – Тугаш автомобиль юлы буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, Каран елгасын кисеп үтеп, 450 м төньяк-көнчыгышка таба бара, сынык сызык ясап, 500 м төньякка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 202 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 2,0 км төньяк-көнбатышка таба 95, 92, 87 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 200 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба 81 нче, 82 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 350 м көнбатышка таба 78 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 400 м төньяк-көнбатышка таба 78 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, 78 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м уза, алга таба 200 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м 77 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
15 нче кушымта

## Минзәлә муниципаль районының «Яңа Маҗын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Яңа Маҗын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»

Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Мажын авыл җирлеге Кадрәк, Николаевка, Юшады авыл җирлекләре һәм Мөслим муниципаль районы белән чиктәш.

Яңа Мажын авыл җирлеге чиге Кадрәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Мажын, Кадрәк һәм Юшады авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Мунча авылыннан 3,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып 2,7 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Яңа Мажын, Кадрәк авыл җирлекләре, Мөслим һәм Сарман муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Иске Мунча авылыннан 3,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче (69 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Мажын авыл җирлеге чиге Юшады авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешләрне һәм текә ярны кисеп үтеп, 2,8 км көнчыгышка таба, 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба Яңа Мажын, Юшады һәм Николаевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Караны авылыннан 3,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Мажын авыл җирлеге чиге Николаевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Мажын, Николаевка авыл җирлекләре һәм Мөслим муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Мажын авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча 1,0 км өскә таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 50 м агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 50 м көньяк-көнбатышка таба агач-куак массивының көнчыгыш чиге буйлап уза, төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлык буенча, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, канауны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м сазлыкның көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 400 м көньяк-көнбатышка таба, канауны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, көнбатышка таба 1,2 км сазлыкның көньяк чиге буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 1,0 км сазлыкның көньяк чиге буйлап уза, төньяк-

көнбатышка таба, Минзәлә – Рус Караны – Тугаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасы буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Маҗын авыл җирлеге чиге Мөслим муниципаль районы белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап 33 нче (69 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
16 нчы кушымта

**Минзәлә муниципаль районының «Яңа Мәлкән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Яңа Мәлкән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картасхемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге Аю, Бикбау, Воровский авыл җирлекләре һәм Актаныш муниципаль районы белән чиктәш.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге чиге Актаныш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Яңа Мәлкән, Воровский авыл җирлекләре һәм Актаныш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Дусай-Кичү авылыннан 5,8 км төньякта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап Яңа Мәлкән, Бикбау авыл җирлекләре һәм Актаныш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Дусай-Кичү авылыннан 5,7 км төньяккөнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге чиге Бикбау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Яңа Мәлкән, Бикбау һәм Аю авыл җирлекләре

чикләре тоташкан урында Куян авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 900 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм төньяк-көнчыгышка таба 250 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км, сазлык буенча 100 м бара, алга таба, агач-куак массивын һәм сазлыкны кисеп үтеп, 1,4 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 350 м күл буенча, агач-куак массивын кисеп үтеп, 250 м сазлык буенча, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 150 м сазлык буенча, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 200 м сазлык буенча, 150 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны, Ык елгасын кисеп үтеп, 200 м агач-куак массивы буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, 200 м күлнең көнбатыш чиге буйлап, күлне кисеп үтеп, 300 м сазлык буенча, 150 м агач-куак массивы буйлап, 200 м сазлык буенча, 750 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 150 м сазлык буенча, 50 м күл буенча, 200 м сазлык буенча, 150 м күл буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сазлык буенча, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м агач-куак массивы буйлап 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге чиге Аю авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып көнбатышка таба 150 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 4,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, кибеп баручы инеш агымы буенча 650 м өскә таба бара, аннары 600 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 2,6 км көньяк-көнбатышка таба, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 113, 115, 114 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 700 м төньяк-көнбатышка таба 114 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 700 м көньяк-көнчыгышка таба, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 116 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 116 нчы урман кварталының

көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,4 км төньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 116, 114, 110 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 107 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км көньяк-көнбатышка таба һәм көнбатыш чиге буйлап, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба уза, ике тапкыр Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба һәм 50 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары, сынык сызык ясап, 200 м төньякка таба 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 50 м, 107 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 50 м Яңа Мәлкән, Аю һәм Воровский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дружба авылыннан 650 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге чиге Воровский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба, агач-куак массивын кисеп үтеп, 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 850 м сазлык буенча, 2,6 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 50 м сазлык буенча, 50 м агач-куак массивы буйлап, 250 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 300 м сазлык буенча, 400 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап, 200 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 300 м сазлык буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 950 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 950 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, аннары инеш агымы буенча 750 м өскә таба буага кадәр бара, 300 м көньяк-көнбатышка таба буа буенча бара, алга таба инеш агымы буенча 2,3 км өскә таба уза, көньяк-көнчыгышка таба, инешнең текә уң ярын һәм «Мәскәү — Уфа» — Яңа Мәлкән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 178 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, 1,2 км төньяк-көнбатышка таба, «Мәскәү — Уфа» — Яңа Мәлкән автомобиль

юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 101 нче, 100 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба 2,7 км көньяк-көнбатышка таба, «Мәскәү – Уфа» – Яңа Мәлкән автомобиль юлына һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 100, 102, 103, 104, 105, 108 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 107 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м төньяк-көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 650 м көньяк-көнбатышка таба 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
17 нче кушымта

## Минзәлә муниципаль районының «Тауасты Байлар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Тауасты Байлар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Тауасты Байлар авыл җирлеге «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Коноваловка, Ырыс һәм Юртово авыл җирлекләре белән чиктәш.

Тауасты Байлар авыл җирлеге чиге Ырыс авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Тауасты Байлар, Ырыс һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Ашпала авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 600 м урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасы буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-

көнбатыш чиге буйлап, урман полосаларын һәм Минзәлә – Боерган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә – Боерган» – Гөлек автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Әүрлән елгасын, яр буе агач-куак массивын, текә ярны кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көнчыгышка таба 450 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 500 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак массивы буйлап уза, сазлыкны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 3,1 км, 100 м сазлык буенча, агач-куак массивын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 150 м сазлык буенча, 150 м агач-куак массивы буйлап, 200 м сазлык буенча, 1,1 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап Тауасты Байлар, Ырыс авыл җирлекләре һәм «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Тауасты Байлар авылыннан 3,7 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Тауасты Байлар авыл җирлеге чиге «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 1,0 км сусаклагычның сул ярына кадәр, яр буе комлыгы буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 151 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм, ике тапкыр чокырларны кисеп үтеп, 250 м көнчыгышка таба, 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба 300 м көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км урман полосасы буйлап уза, көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, 149 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 550 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 149 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м Тауасты Байлар авыл җирлеге, «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Юртово авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Юртово поселогыннан 2,5 км

төньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Тауасты Байлар авыл җирлеге чиге Юртово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көньякка таба, 250 м төньяк-көнбатышка таба, 30 м төньякка таба уза, 950 м төньяк-көнбатышка таба Минзәлә – Боерган автомобиль юлы буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 140, 145, 148 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,8 км бара, алга таба төньяк-көнбатышка, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 148 нче, 147 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 147 нче, 146 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, валны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,9 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м Тауасты Байлар, Юртово һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мияш авылыннан 2,3 км көньякта урнашкан 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Тауасты Байлар авыл җирлеге чиге Коноваловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 5 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 120, 121, 122, 137, 136, 134 нче урман кварталларының төньяк, төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш, көнбатыш чикләре буйлап, Мияш инешен кисеп үтеп, сынык сызык ясап, кибеп баручы инешкә кадәр 5,3 км уза, аннары кибеп баручы инеш агымы буенча 250 м аска таба буага кадәр бара, алга таба, сынык сызык ясап, 550 м төньяк-көнчыгышка таба буаның уң яры буйлап Минзәлә – Боерган автомобиль юлына кадәр уза, 100 м төньяк-көнбатышка таба буа плотинасы буенча узучы әлеге автомобиль юлы буйлап бара, аннары Мияш инеше агымы буенча 600 м аска таба уза, көньяк-көнчыгышка таба 134 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 30 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м бара, аннары 134 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап, Минзәлә – Боерган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,9 км көньяк-көнбатышка таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 136 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, 136 нчы урман

кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 650 м көньяк-көнчыгышка таба уза, көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 136 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 500 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 136 нчы, 137 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км уза, 500 м төньяк-көнбатышка таба 137 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 950 м көньякка таба 122 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 1,2 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 4 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
18 нче кушымта

**Минзәлә муниципаль районының «Иске Маҗын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Маҗын авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Маҗын авыл җирлеге «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Аю, Воровский, Коноваловка, Николаевка, Юртово һәм Юшады авыл җирлекләре белән чиктәш.

Иске Маҗын авыл җирлеге чиге Юртово авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Маҗын, Юртово һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Белопахотный поселогыннан 2,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 250 м сазлык буенча, кибеп ба-

ручы инешне һәм Елховка елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 4,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Иске Маҗын, Юртово авыл җирлекләре һәм «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Юртово поселогыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Маҗын авыл җирлеге чиге «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 13 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 950 м сазлык буенча, агач-куак полосасын һәм дамбаны кисеп үтеп, 1,5 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап Иске Маҗын авыл җирлеге, «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Воровский авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Воровский ис. совхоз поселогыннан 2,4 км көнбатышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан X=467602,19, Y=2368637,23 координаталы 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Маҗын авыл җирлеге чиге Воровский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Маҗын, Воровский һәм Аю авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дружба авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнбатышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 4, 2, 1 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 183 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 150 м төньяк-көнчыгышка таба, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 179 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 550 м төньякка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км аска таба бара, төньяк-көнбатышка таба 20 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын һәм текә ярны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 550 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 14 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Маҗын авыл җирлеге чиге Аю авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Маҗын, Аю һәм Николаевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чулпан авылыннан 1,9 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан

Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 50 нче, 44 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба 36 нчы, 37 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, алга таба төньякка таба 38 нче, 31 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 1,4 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м, 31 нче һәм 32 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 650 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 22, 16, 10, 5 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 3,9 км 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Маҗын авыл җирлеге чиге Николаевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Маҗын, Николаевка һәм Юшады авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чулпан авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 77, 79, 83 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 3,1 км төньяк-көнчыгышка таба 84, 80, 70, 56 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 550 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 600 м төньяк-көнчыгышка таба 57 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Маҗын авыл җирлеге чиге Юшады авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 55 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 198 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м уза, көньяк-көнчыгышка таба 300 м әлеге аерымланган кишәрлекнең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 1,4 км аска таба уза, алга таба 30 м төньяк-көнбатышка таба урман массивы буйлап бара, аннары төньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба көнбатышка, Минзәлә – Рус Караны – Тугаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының

көньяк чиге буйлап, 50 м урман полосасы буйлап, 150 м карьер буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 121 нче, 120 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 2,1 км бара, 150 м урман массивының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тупач елгасына кадәр, кибеп баручы инешне һәм бу елганың текә уң ярын кисеп үтеп, Иске Маҗын, Юшады һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тупач авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта Тупач елгасында урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Маҗын авыл җирлеге чиге Коноваловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып, сынык сызык ясап, 3,5 км көньяк-көнбатышка таба, Ашпала елгасын һәм кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 100 м төньяк-көнбатышка таба агач-куак массивы буйлап бара, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярны ике тапкыр кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 150 м төньяк-көнбатышка таба агач-куак массивы буйлап бара, 150 м көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куак массивы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 100 м агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба буа буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба, текә ярларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 450 м агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, агач-куак массивын һәм «Мәскәү — Уфа» — Тупач автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м көньяк-көнбатышка таба һәм, Минзәлә елгасын һәм сазлыкны кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба, текә ярны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 450 м көньяк-көнбатышка таба, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 184 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 20 м уза, әлеге аерымланган кишәрлекнең көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 800 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, алга таба көньяк-көнчыгышка 184 нче ур-

ман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 650 м, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, 20 м көньякка таба урман массивы буйлап уза, төньяк-көнчыгышка таба 119 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м бара, 700 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мәскәү — Уфа» — Тупач автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Тупач елгасын кисеп үтеп, 150 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 199 нчы урман кварталының һәм 124, 125, 126 нчы урман кварталларының аерымланган кишәрлекләренең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 4,8 км уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 126 нчы, 128 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 4,3 км уза, 129 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м бара, 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба 129 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба умарталык буйлап 150 м, 129 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м уза, алга таба көньяк-көнбатышка 129 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м һәм көньяк чиге буйлап 600 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 700 м, 129 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 200 м уза, текә ярны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м чокыр төбе буйлап, 850 м көньякка таба буа буйлап, Тупач елгасы буенча 1,3 км өскә таба 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
19 нчы кушымта

## Минзәлә муниципаль районының «Иске Матвеевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Иске Матвеевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картасхемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»

Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Иске Матвеевка авыл җирлеге Аю, Бикбау, Иркәнәш, Николаевка авыл җирлекләре һәм Актаныш муниципаль районы белән чиктәш.

Иске Матвеевка авыл җирлеге чиге Актаныш муниципаль районы белән чиктәш җирдә Иске Матвеевка, Бикбау авыл җирлекләре һәм Актаныш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бикбау авылыннан 4,0 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 21 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап Иске Матвеевка, Иркәнәш авыл җирлекләре һәм Актаныш муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яту авылыннан 1,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Матвеевка авыл җирлеге чиге Иркәнәш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Матвеевка, Иркәнәш һәм Николаевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Үртамак авылыннан 1,7 км көнчыгышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып 100 м көнчыгышка таба агач-куак массивы буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 2,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба көньяк-көнчыгышка 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ык елгасына кадәр, бу елганы кисеп үтеп, 50 м, чокырны кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Иске Иркәнәш – Татар Мөшегесе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Матвеевка авыл җирлеге чиге Николаевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Матвеевка, Николаевка һәм Аю авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Степановка авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,3 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, алга таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, Иске Матвеевка – Николаевка – Рус Караны автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосаларын кисеп үтеп, 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының төньяк-

көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Иске Матвеевка авыл җирлеге чиге Аю авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Иске Матвеевка, Аю һәм Бикбау авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Аю авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 42 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл буе урман полосасын кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 850 м төньяк-көнбатышка таба уза, аннары 600 м көньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Камышлы елгасын кисеп үтеп, 500 м көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба 700 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 6,0 км көньяк-көнбатышка таба, «Мәскәү – Уфа» – Иске Матвеевка автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны, агач-куак массивын һәм урман полосасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Иске Матвеевка авыл җирлеге чиге Бикбау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба, сазлыкны кисеп үтеп, 150 м күл буенча, берничә тапкыр күлләрне һәм сазлыкны кисеп үтеп, 1,1 км агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м агач-куак массивы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, күлне кисеп үтеп, 50 м агач-куак массивы буйлап, 50 м күл буенча, агач-куак массивын кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 650 м агач-куак массивы буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м агач-куак массивы буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак массивы буйлап, 300 м сазлык буенча, күлне кисеп үтеп, 50 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м

агач-куак массивы буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м сазлык буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлык буенча, күлне кисеп үтеп, 50 м агач-куак массивы буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сазлыкны, күлне һәм ике тапкыр агач-куак массивын кисеп үтеп, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, ике тапкыр агач-куак массивын кисеп үтеп, 350 м күлнең көнбатыш чиге буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м сазлык буенча, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, күлне кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярны кисеп үтеп, 100 м күлнең көнбатыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ык елгасына кадәр уза, бу елганы һәм аның текә сул ярын кисеп үтеп, 100 м, 1,3 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, 1,1 км төньяк-көнбатышка таба, урман полосасын һәм «Мәскәү – Уфа» – Иске Александровка – Бикбау автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,7 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көньяк-көнбатышка таба 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 1,1 км көнбатышка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 600 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы Камышлы елгасын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,1 км төньяк-көнбатышка таба Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 42 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
20 нче кушымта

**Минзәлә муниципаль районының «Ырыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Ырыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Ырыс авыл җирлеге «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Коноваловка, Хуҗамәт, Тауасты Байлар авыл җирлекләре, Әгерҗе һәм Тукай муниципаль районнары белән чиктәш.

Ырыс авыл җирлеге чиге Тукай муниципаль районы белән чиктәш җирдә Ырыс, Хуҗамәт авыл җирлекләре һәм Тукай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Бакчасарай авылыннан 2,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап Ырыс авыл җирлеге, Тукай һәм Әгерҗе муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Гөлек авылыннан 12,7 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 1 нче (67 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Ырыс авыл җирлеге чиге Әгерҗе муниципаль районы белән чиктәш җирдә 1 нче (67 нче) тоташу ноктасыннан алып Минзәлә муниципаль районы чиге буйлап Ырыс авыл җирлеге, «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Әгерҗе муниципаль районы чикләре тоташкан урында Гөлек авылыннан 11,2 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 2 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ырыс авыл җирлеге чиге «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба, берничә тапкыр агач-куак массивын, сазлыкны һәм күлне кисеп үтеп, 2,6 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м агач-куак массивы буйлап, 200 м сазлык буенча, сазлыкны

кисеп үтеп, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 550 м агач-куак массивы буйлап, 150 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 350 м агач-куак массивы буйлап, 100 м сазлык буенча, 150 м күл буенча, 150 м агач-куак массивы буйлап, 150 м күл буенча, ике тапкыр сазлыкны кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап, 50 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 450 м агач-куак массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м агач-куак массивы буйлап, 150 м сазлык буенча, 600 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 200 м сазлык буенча, 150 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 100 м агач-куак массивы буйлап, 200 м сазлык буенча, 500 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 50 м агач-куак массивы буйлап, агач-куак массивын кисеп үтеп, 300 м сазлык буенча, 200 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 150 м сазлык буенча, 300 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 200 м сазлык буенча, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 200 м сазлык буенча, сазлыкны кисеп үтеп, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 450 м агач-куак массивы буйлап, 100 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 150 м агач-куак массивы буйлап, 300 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, сазлыкны, агач-куак массивын һәм полосасын кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,5 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап Ырыс авыл җирлеге, «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тауасты Байлар авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Тауасты Байлар авылыннан 3,7 км төньяк-көнчыгышта Түбән Кама сусаклагычы акваториясендә урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Ырыс авыл җирлеге чиге Тауасты Байлар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ырыс, Тауасты Байлар һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Ашпала авылыннан 2,0 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 5 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 600 м урман полосасы буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 750 м урман полосасы буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, урман полосаларын һәм Минзәлә – Боерган автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп,

1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә — Боерган» — Гөлек автомобиль юлы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, Әүрлән елгасын, яр буе агач-куак массивын, текә ярны кисеп үтеп, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көнчыгышка таба 450 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м урман полосасы буйлап, 500 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м агач-куак массивы буйлап уза, сазлыкны һәм агач-куак массивын кисеп үтеп, Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 3,1 км, 100 м сазлык буенча, агач-куак массивын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап, 150 м сазлык буенча, 150 м агач-куак массивы буйлап, 200 м сазлык буенча, 1,1 км Түбән Кама сусаклагычы акваториясе буйлап 3 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ырыс авыл җирлеге чиге Коноваловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Ырыс, Коноваловка һәм Хуҗамәт авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бакчасарай авылыннан 2,6 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, урман массивын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м урман массивы буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 200 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 5 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Ырыс авыл җирлеге чиге Хуҗамәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып 450 м көньяк-көнчыгышка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 97 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы Сөрмәт елгасына кадәр уза, бу елга агымы буенча 1,2 км аска таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 99 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 30 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 50 м, 99 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, аннары, сынык сызык

ясап, 400 м көнчыгышка таба, кибеп баручы Сөрмәт елгасын кисеп үтеп, 99 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 20 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 250 м көньяк-көнбатышка таба бара, 99 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 200 м бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, сынык сызык ясап, 99 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 300 м уза, аннары 100 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м төньяк-көнчыгышка таба һәм төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, көньякка таба 100 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, алга таба 100 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Яңа Александровка – Тулыбай автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 650 м бара, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба 101 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 6 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
21 нче кушымта

## Минзәлә муниципаль районының «Юртово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Юртово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Юртово авыл җирлеге «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге, Коноваловка, Тауасты Байлар һәм Иске Мажын авыл җирлекләре белән чиктәш.

Юртово авыл җирлеге чиге «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Юртово авыл җирлеге, «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Тауасты Байлар авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Юртово поселогыннан

2,5 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба Минзәлә — Боерган автомобиль юлы буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба, 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, алга таба 2,2 км көньяк-көнбатышка таба Минзәлә шәһәрен әйләнеп үтүче автомобиль юлы буйлап уза, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлы буйлап Юртово авыл җирлеге, «Минзәлә шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Иске Маҗын авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Юртово поселогыннан 1,9 км көнчыгышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Юртово авыл җирлеге чиге Иске Маҗын авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юртово, Иске Маҗын һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Белопахотный поселогыннан 2,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м агач-куак массивы буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 250 м сазлык буенча, кибеп баручы инешне һәм Елховка елгасын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 4,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Юртово авыл җирлеге чиге Коноваловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юртово, Коноваловка һәм Тауасты Байлар авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Мияш авылыннан 2,3 км көньякта урнашкан 4 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньяк-көнбатышка таба бара, алга таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 128 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м уза, аннары 400 м көньяк-көнчыгышка таба 132 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 50 м 199 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 3,2 км көньяк-көнчыгышка таба, Мәскәү — Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Юртово авыл җирлеге чиге Тауасты Байлар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 15 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м көньякка таба, 250 м төньяк-көнбатышка таба, 30 м төньякка таба уза, 950 м төньяк-көнбатышка таба Минзәлә — Боерган автомобиль юлы буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап 500 м, «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Юртово участок урманчылыгындагы 140, 145, 148 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,8 км бара, алга таба төньяк-көнбатышка, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 148 нче, 147 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 147 нче, 146 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, валны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,9 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 300 м 4 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Минзәлә муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
22 нче кушымта

**Минзәлә муниципаль районының «Юшады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Юшады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Юшады авыл җирлеге Кадрәк, Коноваловка, Николаевка, Яңа Маҗын һәм Иске Маҗын авыл җирлекләре белән чиктәш.

Юшады авыл җирлеге чиге Иске Маҗын авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юшады, Иске Маҗын һәм Николаевка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чулпан авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, 55 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 198 нче урман кварталының аерымланган

кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м уза, көньяк-көнчыгышка таба 300 м әлеге аерымланган кишәрлекнең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, бу инеш агымы буенча 1,4 км аска таба уза, алга таба 30 м төньяк-көнбатышка таба урман массивы буйлап бара, аннары төньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба көнбатышка, Минзәлә – Рус Караны – Тугаш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 50 м урман полосасы буйлап, 150 м карьер буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 121 нче, 120 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 2,1 км бара, 150 м урман массивының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тупач елгасына кадәр, кибеп баручы инешне һәм бу елганың текә уң ярын кисеп үтеп, Юшады, Иске Маҗын һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тупач авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта Тупач елгасында урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Юшады авыл җирлеге чиге Николаевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юшады, Николаевка һәм Яңа Маҗын авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Караны авылыннан 3,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,0 км төньяк-көнбатышка таба, агач-куак массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба бара, 400 м көнчыгышка таба Минзәлә – Рус Караны – Тугаш автомобиль юлы буйлап уза, алга таба төньяк-көнбатышка 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км агач-куак массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, Каран елгасын кисеп үтеп, 450 м төньяк-көнчыгышка таба бара, сынык сызык ясап, 500 м төньякка таба «Минзәлә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 202 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 2,0 км төньяк-көнбатышка таба 95, 92, 87 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 200 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 1,4 км төньяк-көнчыгышка таба 81 нче, 82 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 350 м көнбатышка таба 78 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 400 м төньяк-көнбатышка таба 78 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары

төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, 78 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м уза, алга таба 200 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, төньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м 77 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Юшады авыл җирлеге чиге Яңа Мажын авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юшады, Яңа Мажын һәм Кадрәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Мунча авылыннан 3,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешләрне һәм текә ярны кисеп үтеп, 2,8 км көнчыгышка таба, 1,8 км төньяк-көнчыгышка таба 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Юшады авыл җирлеге чиге Кадрәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Юшады, Кадрәк һәм Коноваловка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Җәмәк авылыннан 1,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып 300 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Вязовка елгасына кадәр уза, шуннан соң бу елга агымы буенча 350 м өскә таба бара, аннары көнчыгышка таба 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, инешне, урман полосасын һәм Минзәлә – Рус Караны – Тугаш автомобиль юлын Зур Нөркәй – Кадрәк автомобиль юлы белән тоташтыручы профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 600 м төньяк-көнчыгышка таба әлеге профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 600 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 20 м агач-куак массивы буйлап инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 650 м аска таба бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м, чокырны кисеп үтеп, агач-куак массивы буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м чокыр буйлап, сынык сызык ясап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Минзәлә елгасына кадәр, аның текә уң ярын кисеп үтеп, Минзәлә елгасы агымы буенча 4,2 км өскә таба уза, алга таба 4,0 км көньяк-көнчыгышка таба, Минзәлә елгасының текә уң ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 34 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Юшады авыл җирлеге чиге Коноваловка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Тупач елгасы агымы буенча 1,0 км өскә таба кибеп баручы инеш та-

магына кадәр уза, бу инеш агымы буенча 300 м өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешнең текә уң ярын кисеп үтеп, 1,9 км көньяк-көнчыгышка таба, текә ярларны кисеп үтеп, 1,6 км көньяк-көнбатышка таба, 100 м чокыр буенча, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2014 елның 22 ноябре
№ 105-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1208. «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 8 (III өлеш), 2 — 13 кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Ютазы муниципаль районы» муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

## «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

«Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкортостан Республикасы, Азнакай, Баулы, Бөгелмә муниципаль районнары белән чиктәш.

«Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге Башкортостан Республикасы белән чиктәш җирдә Ютазы, Азнакай муниципаль районнары һәм Башкортостан Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Каразирек авылыннан 1,9 км төньяк-көнбатышта урнашкан 6 нчы (22 нче) тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Ютазы, Баулы муниципаль районнары һәм Башкортостан Республикасы чикләре тоташкан урында Екатериновка поселогыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта Ык елгасы акваториясендә урнашкан 20 нче (23 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

«Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 20 нче (23 нче) тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 50 м агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 300 м агач-куак үсемлекләре массивының төньяк чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м үзәнлектәге сазлык буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,3 км, күлне кисеп үтеп, 800 м көньяк-көнбатышка таба «Урыссу – Октябрьский» – Әбсәләм – Уба автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, 250 м көньяк-көнбатышка таба әлеге автомобиль юлы буйлап үтә, Куйбышев тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, «Урыссу – Октябрьский» – Әбсәләм – Уба автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлы буйлап уза, алга таба 2,3 км

көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,7 км көньяк-көнбатышка таба Мәскәү – Чиләбе федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап бара, 700 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 450 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньякка таба 800 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 700 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 1,9 км профильле автомобиль юлы буйлап Дымка елгасына кадәр бара, 11,3 км әлеге елга агымы буенча өскә таба уза, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м үзәнлектәге сазлык буйлап буа плотинасына кадәр бара, алга таба, сынык сызык ясап, 550 м төньякка таба буа плотинасы буенча бара, әйләнгеч каналны кисеп үтә, сынык сызык ясап, 550 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 2,4 км көньяк-көнбатышка таба Бөгелмә – Ютазы автомобиль юлы буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Кырым Сарай елгасына кадәр бара, аннары 1,1 км әлеге елга агымы буенча аска таба уза, алга таба 20 м төньяк-көнчыгышка таба агач-куак үсемлекләре массивы буйлап, 1,5 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,3 км төньякка таба һәм сынык сызык белән 1,5 км төньяк-көнбатышка таба бара, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 400 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап уза, алга таба 1,5 км төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Ютазы, Баулы һәм Бөгелмә муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Еновка авылыннан 3,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче (75 нче) тоташу ноктасына кадәр бара.

«Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чиге «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Ютазы, Бөгелмә һәм Азнакай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Урал поселогыннан 3,8 км төньякта урнашкан 1 нче (74 нче) тоташу ноктасыннан алып 400 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 150 м «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ютазы участок урманчылыгындагы 51 нче урман кварталының аерымланган участогының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 300 м көньяк-көнбатышка таба, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба 250 м 194 нче урман кварталының

аерымланган участогының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, сынык сызык ясап, 1,2 км көньякка таба «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 61 нче урман кварталының һәм 64 нче урман кварталының аерымланган участогының көнчыгыш чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 150 м көнчыгышка, 50 м көньяк-көнчыгышка таба 64 нче урман кварталының аерымланган участогының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м 64 нче урман кварталының аерымланган участогының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 250 м көньякка таба 64 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, алга таба 150 м 64 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Аргаги инешен кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 400 м көньяк-көнбатышка таба 64 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк чиге буйлап бара, төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м 64 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк чиге буйлап, 100 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 64 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 300 м 62 нче урман кварталының аерымланган участогының көньяк чиге буйлап уза, алга таба көньяк-көнбатышка таба 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м агач-куак үсемлекләре полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, 250 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, Рудный Дол елгасын кисеп үтеп, 150 м «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ютазы участок урманчылыгындагы 194 нче урман кварталының аерымланган участогының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, алга таба 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 250 м көнчыгышка таба «Бөгелмә урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Актүбә участок урманчылыгындагы 66 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Самбай елгасына кадәр уза, алга таба 1,9 км әлеге елга агымы буенча өскә таба, инешне кисеп үтеп, 1,3 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м

